A. T. S. S. C. Qazan LENIN isem. BILGE MASSA KITAPXANSE TEP KITAP SAQLAV BYLEGE
ОСНОВНОЕ КНИГОХРАНИЛИЩЕ ОБЛАСТНОЙ МАССОВОЙ БИБЛИОТЕКИ ИМ. ЛЕНИНА ТАССР г. Казань

ДҮШӘМБЕ
11 МАРТ
1940 ел
№ 58 (5858)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ: Казан, Матбугат йорты.
ТЕЛЕФОННАР: экономик бүлек 18—22, авыл хуҗалыгы һәм совет төзелеше бүлекләре 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—23, культура бүлеге 18—22, информация бүлеге 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игланнар бүлеге 2—19.

ИПТӘШ В. М. МОЛОТОВКА

Кадерле Вячеслав Михайлович!

ВКП(б) ның Татарстан оешмасының XXI нче өлкә конференциясе Сезгә, Ленин һәм Сталинның турылыклы көрәштәшенә, большевиклар партиясенең һәм социалистик дәүләтнең иң күренекле оештыручысына һәм җитәкчесенә, сөекле Совет хөкүмәте башлыгына большевикларча кайнар сәлам җибәрә.

Сез, Вячеслав Михайлович, яшьтән үк данлыклы һәм кыен юлга—пролетар революционер юлына бастыгыз. Беренче революция елларында һәм кара реакция елларында Сез Казан большевиклары оешмасын оештыручыларның берсе, ә соңыннан аның турыдан-туры җитәкчесе дә булдыгыз, революцион студентлар арасында, эшчеләр массасы арасында армый - талмый гаять зур эш алып бардыгыз. Сез большевизм байрагын куркусыз рәвештә югары тоттыгыз, эшчеләрне капитализмга һәм самодержавиегә каршы көрәшкә тупладыгыз. Сез большевиклар оешмасын Ленин—Сталин эшенә чын күңелдән бирелгәнлек рухында, халык дошманнарына карата килешмәүчән нәфрәт рухында көн саен тәрбияләп килдегез.

Сезнең—кристаллдай саф һәм ныклы большевикның гүзәл тормышы партиябезнең героик тарихы белән аерылгысыз булып бәйләнгән. Ленин һәм Сталин белән берлектә Сез большевиклар партиясен төзедегез, Бөек Октябрь Социалистик Революциясенең җиңүен оештырдыгыз, Совет дәүләтен төзедегез һәм ныгыттыгыз.

Ун ел буена Сез дөньяда беренче булган социалистик держава хөкүмәтенең башында торасыз. Сезнең армый-талмый алып барган партия һәм дәүләт эше Совет дәүләтен шул кадәр ныгытты, аның ныклыгын һәм җиңелмәслеген нинди генә капиталистик ил дә икрар итә. Сезнең җитәкчелегегездә, Сталинның тышкы политикасы ныклы рәвештә тормышка үткәрү нигезендә Европаның көнчыгышында ныклы тынычлык тәэмин ителде, тынычлык сөюче барлык илләр белән дуслык һәм яхшы күршелек мөнәсәбәтләре урнаштырылды, Советлар Союзының халыкара авторитеты һәм әһәмияте үлчәүсез күтәрелде.

Сезнең илле еллыгыгызны бөтен совет халкы, бөтен партиябез, бөтен дөньяның хезмәт ияләре искә алып үтәләр. Без, партиянең Татарстан оешмасының XXI нче өлкә конференциясе делегатлары, бөтен партия оешмасы исеменнән, орденлы Татарстанның барлык хезмәт ияләре исеменнән Сезне котлыйбыз һәм Сезгә, Вячеслав Михайлович, озак һәм озак еллар сәламәтлек телибез, Ватаныбыз файдасына, халкыбыз файдасына тагын да нәтиҗәле эшләвегезне телибез.

Яшәсен җиңелмәслек Ленин—Сталин партиясе!
Яшәсен Совет хөкүмәте башлыгы Вячеслав Михайлович Молотов!
Яшәсен туганыбыз, сөеклебез бөек Иосиф Виссарионович Сталин!

ВКП(б) ның Татарстан оешмасының XXI нче өлкә конференциясе.

ВКП (б) ның Татарстан оешмасының XXI нче өлкә конференциясендә. М. Солтанов фотосы.

Партиянең Татарстан оешмасының XXI нче Өлкә Конференциясе ачылды

Иптәш А. М. Алемасовның конференцияне ачканда сөйләгән рече

Иптәшләр!

Партия органнарына булган үткән сайлаулардан соң егерме ай вакыт үтте. Егерме айлык тарихи вакыт шактый кыска, ләкин ул вакыйгаләргә чиксез бай, алар белән тулы, бу вакыйгалар социалистик дәүләтебезнең, большевистик партиябезнең бөек җиңүләре сыйфатында кешелек дөньясы тарихына керәчәкләр.

Бу чор эчендә бөтен дөнья безнең социалистик Ватаныбызның ныклыгы, какшамаслыгы һәм җиңелмәслеге турында күп кенә дәлилләр алды, СССР ның бөтен дөньяда тынычлык терәге икәнлеге һәм шулай булып калачагы турында күп дәлилләр алды.

Көнчыгыштагы канлы ерткычлар акыллары тупас булганлыктан моны аңламыйча безнең илебезнең куәтен сынарга, аның тышкы политикасын сынарга маташып карадылар. Бу маташуларның нәтиҗәләрен бөтен дөнья белә. Социализм иленең тышкы политикасы какшамаслык булып калды, ә Хасан күле янында һәм Халхин-Гол ярларында ерткыч самурайларны тәмам тар-мар итү белән безнең Эшче-Крестьян Кызыл Армиясе үзенә бетмәс дан һәм героизм казанды. **(Кул чабулар).** Башкача нәтиҗәнең булуы мөмкин дә түгел иде. Шуның өчен мөмкин түгел иде, чөнки безнең тышкы политикабыз төзелешенә, безнең Эшче-Крестьян Кызыл Армиясе төзелешенә бөтен дөньяның иң яхшы дусты—бөек Сталин җитәкчелек итә. **(Залдагылар барсы да урыннарыннан торалар, кул чабулар, кул чабулар көчле алкышларга күчә. Ура! Яшәсен иптәш Сталин!—дигән тавышлар).**

Англиянең, Франциянең һәм Американың империалистик акулалары, социалистик дәүләтне юк итү теләге белән, бер яктан Советлар Союзы халкы белән, икенче яктан Германия халкы белән сугыш бәрелеше китереп чыгарырга барлык чаралар белән омтылдылар. Бу теләккә ирешү өчен кабахәт яла ягулар, тиңдәшсез ике йөзлелек һәм провокацияләр—бөтенесе ходка җибәрелде. Ләкин империалистларның исәпләре барып чыкмады. Канлы провокаторларны, сугыш уты кабызучыларны бөек Сталинның даһи акылы бөтен дөнья алдында фаш итте. **(Озакка сузылган кул чабулар).**

Нәтиҗәдә Совет Социалистик Республикалар Союзы Германия халкы белән дуслык турында договор төзеде. Империалистларның ерткычлыкларына да карамастан, СССР ның чикләре көнбатышка таба киңәйтелде, ә безнең 13,5 миллион украинлы һәм белорус туганнарыбыз үзләренең туган семьясенә кайтарылдылар. **(Кул чабулар).**

Бу бөек гаделлек актыннан социализмның дошманнары басып алу политикасында Советлар Союзын гаепләү өчен файдаланырга маташып карадылар. Ләкин дошманнар бу юлы да исәпләрендә ялгыштылар. Социалистик дәүләт булган СССР Латвия, Эстония, Литва һәм Финляндиянең демократик республикасы арасында үзара ярдәмләшү турында договорлар төзеп, үзенең әзлекле тынычлык политикасын яңадан бер тапкыр күрсәтте.

Совет хөкүмәте үзенең тынычлык политикасын Литвага Вильно өлкәсен һәм демократик Финляндиягә Карелия республикасы территориясенең бер өлешен кушу факты белән беркетте.

Безнең батыр Кызыл Армиябезнең һәм Хәрби Диңгез Флотының сугышчылары үз якларыннан договор йөкләмәләрен намус белән үтәп фин ак гвардеецларын җиңеп, тар-мар итәләр, демократик Финляндия территориясен бу канлы бандалардан чистарталар, Финляндиянең хезмәтчел халкына бәхет һәм азатлык алып киләләр. **(Кул чабулар).**

Бу чор эчендә социализм иленең авторитеты һич кайчан булмаганча үсте. Бөтен дөньядагы барлык хезмәт ияләренең һәм изелгәннәрнең социалистик дәүләткә ышанычлары һич кайчан күрелмәгәнчә көчәйде һәм ныгыды. Үзләренең дустына һәм остазына—бөек Сталинга аларның мәхәббәте тагын да көчәйде. **(Көчле кул чабулар).**

Иптәшләр! Моннан нак бер ел элек шушы көнне һәм шушы сәгаттә большевистик партиябезнең тарихи XVIII нче съезды үзенең эшен башлады. Бу съездның карарлары, иптәш Сталинның съезддагы докладында, социализмнан коммунизмга күчү юлында җәмгыятебезнең тагын да алга баруында аның гаять зур перспективаларын куәтле прожектор булып яктырттылар. Бу чор эчендә „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“ басылып чыгу нәтиҗәсендә марксизм-ленинизм тәглиматы белән, партиянең XVIII нче съезды карарлары белән коралланган Советлар Союзы хезмәт ияләре, большевиклар партиясе җитәкчелегендә, үзләренең күп яклы дәүләт эшенең барлык тармакларында күп кенә яңа гүзәл җиңүләргә ирештеләр.

Шушы җиңүле рәвештә алга баруда социалистик Ватаныбыздагы күп милләтле бөек халыкның үзенең большевистик партиясенә, үзенең дустына, остазына—иптәш Сталинга карата мәхәббәте һәм бирелгәнлеге үсте һәм ныгыды.

Бу мәхәббәт һәм бирелгәнлек союзный һәм автономияле республикаларның Верховный Советларына сайлауларда, хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына сайлауларда коммунистларның һәм партиясезләрнең Сталинчыл блогының гүзәл җиңүендә ачык чагылдылар. Алар иптәш Сталинның 60 еллыгы уңае белән Советлар Союзының барлык почмакларыннан хезмәт ияләреннән агыла агылып килгән күп меңле котлауларда ачык күренделәр. **(Кул чабулар).**

Шушы гомуми алга бару хәрәкәтендә Татарстан республикасының хезмәт ияләре, үзләренең партия оешмасы җитәкчелегендә, бу чор эчендә промышленностьны тагын да күтәрү, колхоз строен тагын да ныгыту эшендә, культура төзелешен үстерү һәм үзләренең материаль тормыш дәрәҗәсен яхшырту эшендә җидди уңышларга ирештеләр.

Бу чор эчендә партиянең Татарстан оешмасы, үзенең сафларын дошман агентурасыннан, череп таралган һәм ышанычсыз элементлардан чистартып, оешу һәм идея ягыннан тагын да ныгыды. Ул хезмәт ияләренең киң массасы белән үзенең элемтәсен ныгытты һәм киңәйтте, үзенең өлкә күләмендәге XXI нче конференциясенә Ленинчел—Сталинчыл Үзәк Комитет тирәсенә ВКП(б) ның нык тупланган һәм үзенең юлбашчысы һәм остазы иптәш Сталинга чын күңелдән бирелгән бердәм монолит отряды булып килде. **(Көчле кул чабулар).**

Яшәсен орденлы Татарстан большевиклары! **(Кул чабулар).**

Яшәсен ВКП(б)! **(Озакка сузылган кул чабулар).**

Яшәсен бөек Сталин! **(Залдагылар барсы да урыннарыннан торалар, кул чабулар, кул чабулар көчле алкышларга күчә).**

(Конференция материалларының дәвамы 2 нче биттә).

Промышленностьның үрнәк эшләвен тәэмин итик

Партиябезнең тарихи XVIII нче съездында расланган Сталинчыл өченче бишьеллык план промышленностьта хезмәт җитештерүчәнлеген 65 процент үстерүне, продукциянең үзенә төшү бәясен 10 процентка киметүне, 1937 нче ел белән чагыштырганда 20 миллиард сум күләмендә экономия ясауны һәм промышленностьның барлык тармакларында да продукциянең сыйфатын яхшыртуны билгеләде. Һәм төп экономик бурыч итеп, Европаның иң алга киткән капиталистик илләрен һәм Америка Кушма Штатларын экономик яктан да куып җитү һәм узып китү бурычын куйды.

Тарихи съездның сугышчан карарлары белән коралланган хәлдә, республикабызның партияле һәм партиясез большевиклары алда торган бу җаваплы һәм мактаулы бурычларны намус белән үтәү өчен көрәшәләр. Алар хезмәт җитештерүчәнлегенең бишьеллык планын дүрт елда үтәү турында Москва инструментальщиклары чакыруына конкрет эш белән җавап бирәләр.

Партиябезнең XVIII нче съездыннан соң үткән чор республикабызның промышленностен үстерү һәм киңәйтү өлкәсендә кайбер уңышларга ирешү чоры булды.

1940 нчы ел стахановчылык хәрәкәтенең һәм масса активлыгының яңа күтәрелеше белән каршыланды. Бу ел берьюлы берничә станокка хезмәт күрсәтү һәм күп профессияләрне үзләштерү хәрәкәте туды. Казан мехчылары инициативасы буенча башланган республикабызның данлыклы XX еллыгы исемендәге социалистик ярыш белән баетылган бу гүзәл хәрәкәт Маслов, Максимова, Гыйлманов, Насыйров, Гибалин, Малова, Иванова, Жаркова кебек стахановчыларны— күп станокчыларны үстерде, алар яңа нормаларны үзләштереп, заданиене системалы рәвештә ике—өч тапкыр арттырып үтиләр. Бу хәрәкәт производство планнарын арттырып үтәү өчен безнең предприятиеләребездә гаять зур эчке мөмкинлекләр барлыгын ачып салды.

Үрнәк эшнең үрнәк нәтиҗәләре күз алдында. „Спартак“ комбинатының хром заводы һәм утиль цехы, Мехкомбинатның 4 нче номерлы фабрикасы һәм механика заводы, 2 нче һәм 4 нче номерлы тегү фабрикалары, Ленин исемендәге күн заводы кебек байтак кына предприятиеләр үз йөкләмәләрен практик эш белән ныгыталар. Алар Татарстан большевикларының кичә ачылган XXI нче өлкә конференциясен зур уңышлар белән каршылауны тәэмин иттеләр.

Ләкин бу алдынгылар белән бер рәттән, бездә әле артта калучы предприятиеләр дә бар. Гомумән алганда республикабыз промышленносте һич канәгатьләнерлек эшләми. Мәсәлән, узган елгы уңышлар белән масаю аркасында, Вахитов исемендәге җиркомбинат һәм язу машиналары заводы январь, февраль айларында артка чигенделәр, план үтәлешен өзделәр. Казан тимер юлының начар эшләвенең, төзелеш трестларының план үтәлешен 60—70 процентан уздыра алмауларының, Мехкомбинатның февральдә артка чигенүенең төп сәбәпләре нәрсәдә соң?

Моның төп сәбәбе шунда: хезмәт дисциплинасының таркау булуында, партия һәм профсоюз оешмаларының производство мәсьәләләре белән җитәрлек шөгыльләнмәүләрендә, алдынгылар тәҗрибәсенең артта калучыларга күчерелмәвендә.

Наркомат һәм завод, фабрика җитәкчеләренең кайберләре эшкә оператив җитәкчелек итү урнына, кәгазьләр, төрле сводкалар эченә кереп чумганнар. Алар теге яки бу предприятиедә, участкыда эшнең чын торышын үзләре дә ачык итеп белмиләр. ТАССР ның җирле промышленность наркоматы моның ачык мисале. Монда „Красный Путь“, „Победа Труда“ фабрикалары һәм Татполиграф план үтәлешен, уртача алганда, 75—80 процентан арттыра алганнары юк. Шуңа карамастан, наркомат өзеклекнең төп сәбәпләрен тикшерми, эшне юлга салу өчен конкрет чаралар күрми. Нарком иптәш Филимонов җирле промышленность предприятиеләренең начар эшләүләренең һәм район промышленностеның чиктән тыш акырын үсүенең сәбәбен район оешмаларына кайтарып калдырырга омтыла.

Республикабыз промышленностеның гомуми торышы бүгенге көн таләпләреннән артта калуы партия оешмаларыннан бу өлкәдә эш стилен тамырыннан үзгәртеп коруны, производство мәсьәләләре белән җидди шөгыльләнүне таләп итә. Шик юк, ВКП(б) ның XXI нче өлкә конференциясе бу турыда үзенең большевистик фикерен әйтер, партия оешмаларыннан промышленность предприятиеләренә җитәкчелек итүне кискен рәвештә яхшыртуны таләп итәр.

„Өченче бишьеллык планның бөек бурычларын тормышка ашыру эшчеләрнең, крестьяннарның һәм совет интеллигенциясенең төп интересларына шул кадәр тыгыз бәйләнгән ки, бу планның үтәлүен тәэмин итү, барыннан да элек, безнең үзебезгә—коммунист һәм партиясез җитәкчеләргә һәм хезмәт ияләрен коммунистик тәрбияләүне күтәрә белүебезгә бәйләнгән“. Тарихи XVIII нче съезд тарафыннан билгеләнгән бу сүзләр безнең производстводагы һәр адымыбызда бердәнбер кулланма булып торырга тиеш.

Иптәш В. М. Молотовның туына 50 ел тулу уңае белән чит ил дәүләтләре эшлеклеләренең котлаулары

СССР Халык Комиссарлары Советы Председателе һәм Чит Ил Эшләре Халык Комиссары иптәш В. М. Молотовның туына 50 ел тулу уңае белән түбәндәгеләрдән котлаулар алынды:

Германиянең чит ил эшләре министре Фон - Риббентроп әфәндедән, Кытайның чит ил эшләре министре Ван Чжун-гуй әфәндедән, Төркиянең чит ил эшләре министре Шөкрү Сараҗоглу әфәндедән, Эстониянең баш министре Улуотс әфәндедән, Эстониянең чит ил эшләре министре Пийп әфәндедән, Эстония армиясенең баш командующие генерал Лайдонердан, Литваның баш министре Меркис әфәндедән, Латвиянең чит ил эшләре министре Мунтерс әфәндедән, Словакиянең чит ил эшләре министре Дурчанский әфәндедән, Монголия Халык Республикасының баш министре маршал Чойбалсаннан.

(ТАСС).

ДИПЛОМАТИЯ КОРПУСЫ КОТЛАУЛАРЫ

СССР Халык Комиссарлары Советы Председателе һәм Чит Ил Эшләре Халык Комиссары иптәш В. М. Молотовның туына 50 ел тулу уңае белән түбәндәгеләрдән котлаулар алынды:

Германиянең гадәттән тыш һәм тулы хокуклы илчесе Фондер Шуленбург әфәндедән, Иранның гадәттән тыш һәм тулы хокуклы илчесе Г. Саэд әфәндедән, Япониянең гадәттән тыш һәм тулы хокуклы илчесе Ш. Того әфәндедән, Әфганстанның гадәттән тыш һәм тулы хокуклы илчесе Солтан Әхмәтхан әфәндедән, Америка Кушма Штатларының гадәттән тыш һәм тулы хокуклы илчесе Л. Штейнгардт әфәндедән, Төркиянең гадәттән тыш һәм тулы хокуклы илчесе Али Хәйдар Актай әфәндедән, Латвиянең гадәттән тыш илчесе һәм тулы хокуклы министре Ф. Коциньш әфәндедән, Монголия Халык Республикасының тулы хокуклы илчесе Самбу әфәндедән, Даниянең гадәттән тыш илчесе һәм тулы хокуклы министре Л. Больт—Иоргенсен әфәндедән, Эстониянең гадәттән тыш илчесе һәм тулы хокуклы министре А. Рей әфәндедән, Бельгиянең гадәттән тыш илчесе һәм тулы хокуклы министре Г. Хейндрикс әфәндедән, Тува Халык Республикасының тулы хокуклы вәкиле Намчак әфәндедән, Литваның гадәттән тыш илчесе һәм тулы хокуклы министре Л. Наткевичиус әфәндедән, Румыниянең гадәттән тыш илчесе һәм тулы хокуклы министре Ж. Давидеску әфәндедән, Норвегиянең гадәттән тыш илчесе һәм тулы хокуклы министре Э. Масенг әфәндедән, Венгриянең гадәттән тыш илчесе һәм тулы хокуклы министре Ж. де Криштоффи әфәндедән, Словакиянең гадәттән тыш илчесе һәм тулы хокуклы министре Ф. Тисо әфәндедән, Болгариянең гадәттән тыш илчесе һәм тулы хокуклы министре Т. Христов әфәндедән, Италия ышанычлысы Л. Машиа әфәндедән, Кытай ышанычлысы Джан Да-Тян әфәндедән һәм Греция ышанычлысы П. Депаста әфәндедән.

ЛЕНИНГРАД ХӘРБИ ОКРУГЫ ШТАБЫНЫҢ ОПЕРАТИВ СВОДКАСЫ

9 нчы мартта фронтта әһәмиятле бер нәрсә дә булмады. Выборг заливында безнең частьләр **Порккансаари** атавын һәм **Пюиспансаари** атавын һәм шул заливның көнбатыш ярында **Карппила** һәм **Рюхеля** местечколарын, ә **Выборгтан** төньяк-көнчыгыштарак **Выборг—Сердоболь** тимер юлындагы **Репола** местечкосын алдылар.

Безнең авиация дошманның гаскәрләренә һәм сугыш объектларына актив хәрәкәтләр алып барды. Шул вакытта дошманның 5 самолеты бәреп төшерелде.

ПАРТИЯНЕҢ ТАТАРСТАН ОЕШМАСЫНЫҢ XXI НЧЕ ӨЛКӘ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ КӨНДӘЛЕГЕ

Кичә кич, нак сәгат 6 да, Казан шәһәренең Менжинский исмендәге клубында ВКП(б) ның Татарстан оешмасының XXI нче өлкә конференциясе ачылды.

Конференцияне ачу алдыннан ВКП(б) Өлкә Комитеты секретаре иптәш **А. М. Алемасов** кыскача речь белән чыкты. Ул үзенең чыгышында отчет чоры эчендә гаять зур политик вакыйгаләргә, социалистик хуҗалыкның барлык тармакларында яулап алынган бөек казанышларга тукталды һәм ВКП(б) ның Татарстан оешмасы үзенең XXI нче өлкә конференциясенә ВКП(б) Үзәк Комитеты тирәсенә, юлбашчыбыз, остазыбыз бөек Сталин тирәсенә тагын да тыгызрак тупланган хәлдә, оештыру һәм идея ягыннан тагын да ныгыган хәлдә килүе турында әйтеп үтте.

Героик Кызыл Армиябезнең Хасан күле һәм Халхин-Гол елгасы янында күрсәткән батырлыклары турындагы, Көнбатыш Украина һәм Көнбатыш Белоруссия халыкларын Польша паннары изүеннән коткару турындагы, Финляндия хезмәт ияләренә азатлык, бәхет китерү өчен бара торган көрәш турындагы сүзләр конференциядә катнашучылар тарафыннан көчле алкышлар белән каршы алынды. Һәм безнең барлык җиңүләребезне оештыручы, яңадан-яңа уңышларга рухландыручы—бөек юлбашчыбыз иптәш Сталин турында әйтелгән сүзләрне бөтен зал аяк өсте басып, озакка сузылган көчле алкышлар белән каршы алды.

Иптәш Алемасовның кереш сүзеннән соң, делегат иптәш **Тихонов** тәкдиме буенча 35 кеше составында бер тавыштан конференциянең президиумы сайлана.

Делегат иптәш **Воробьев** почетлы президиум сайлау турында тәкдим кертә һәм аның бу тәкдиме делегатлар тарафыннан, аяк өсте баскан хәлдә, озакка сузылган көчле алкышлар белән каршы алына. Почетлы президиумга иптәш Сталин җитәкчелегендәге ВКП (б) Үзәк Комитетының Политбюро составы һәм Маленков, Димитров, Тельман иптәшләр сайланалар.

Делегат иптәш **Вахрушев** тәкдиме буенча бер тавыштан 7 кеше составында конференциянең секретариаты һәм делегат иптәш **Захаров** тәкдиме буенча 7 кеше составында мандат комиссиясе сайлана.

Конференциянең көн тәртибен һәм регламентын раслаганнан соң, көн тәртибенең беренче мәсьәләсе буенча—ВКП (б) Өлкә Комитетының эше турындагы отчет өчен ВКП(б) Өлкә Комитеты секретаре иптәш **Алемасовка** сүз бирелә. Иптәш Алемасовның докладын конференция делегатлары зур игтибар белән тыңладылар.

ВКП(б) Өлкә Комитетының эше турында отчет докладыннан соң, конференция делегатлары, Совет хөкүмәте башлыгы иптәш Молотовка 50 яшь тулу уңае белән, аңа көчле кул чабулар астында котлау хаты кабул иттеләр. Шуның белән конференциянең беренче утырышы тәмам булды.

Конференциянең эше шул ук бинада бүген сәгат 11дән дәвам итә.

ПАРТИЯНЕҢ XXI НЧЕ ӨЛКӘ КОНФЕРЕНЦИЯСЕНЕҢ ПОЧЕТЛЫ ПРЕЗИДИУМ СОСТАВЫ

1. Сталин И. В.
2. Молотов В. М.
3. Ворошилов К. Е.
4. Каганович Л. М.
5. Калинин М. И.
6. Андреев А. А.
7. Микоян А. И.
8. Жданов А. А.
9. Хрущев Н. С.
10. Берия Л. П.
11. Шверник Н. М.
12. Маленков Г. М.
13. Димитров Г.
14. Тельман Э.

ПАРТИЯНЕҢ XXI НЧЕ ӨЛКӘ КОНФЕРЕНЦИЯСЕНЕҢ ПРЕЗИДИУМ СОСТАВЫ

1. Абдульманов
2. Алемасов
3. Алексеева
4. Алимова
5. Ариаутов
6. Ахмедуллин
7. Эюпова
8. Бәдретдинов
9. Быков
10. Воробьев
11. Гафиятуллин
12. Гаязетдинов
13. Гринько
14. Динмөхәммәтов
15. Долотказин
16. Зюлина
17. Измайлова
18. Кантюков
19. Каримов
20. Киселев
21. Колесников
22. Крылов
23. Матвеев
24. Мифтахетдинов
25. Михайлин
26. Михайлов
27. Морозов
28. Мөхәметов
29. Петров А.
30. Рундаев
31. Савагин
32. Суганов
33. Тынчеров
34. Хакимжанов
35. Шмельков

ПАРТИЯНЕҢ XXI НЧЕ ӨЛКӘ КОНФЕРЕНЦИЯСЕНЕҢ СЕКРЕТАРИАТ СОСТАВЫ

1. Абдрахманова
2. Анушкин
3. Борщев
4. Жуков
5. Ильин
6. Петров
7. Постнова.

ПАРТИЯНЕҢ XXI НЧЕ ӨЛКӘ КОНФЕРЕНЦИЯСЕНЕҢ МАНДАТ КОМИССИЯСЕ СОСТАВЫ

1. Баһаветдинов
2. Захаров
3. Вахрушев
4. Львов
5. Саланов
6. Тихонов
7. Шульгин

ИПТӘШ В. М. МОЛОТОВНЫҢ ТУУЫНА 50 ЕЛ ТУЛУ УҢАЕ БЕЛӘН КОТЛАУЛАР

ИПТӘШ В. М. МОЛОТОВКА

Кадерле Вячеслав Михайлович!

Сезнең 50 еллыгыгызның тарихи көнендә Сезгә, бөек Сталинның көрәштәшенә, большевистик партиянең турылыклы улына, гүзәл дәүләт эшлеклесенә, безнең Верховный Советыбызның депутатына ялкынлы большевистик сәлам җибәрәбез.

Сезнең бөтен данлы тормышыгыз, Сезнең армас-талмас революцион эшлеклегегез безнең партиябезнең героик тарихы белән, капиталистлар изүеннән котылу өчен халыкларның бөек азатлык көрәше белән, коммунизм төзелеше өчен көрәш белән нык бәйләнгән.

Ленин һәм Сталин белән берлектә Сез, пролетариатны буржуазиягә каршы кискен көрәшкә хәзерләгән һәм Бөек Октябрь Социалистик революциясенең җиңүен оештырган большевистик партияне төзедегез. Ленин һәм Сталин белән берлектә Сез безнең партиябезнең тимер бердәмлеген армый-талмый ныгыттыгыз, партиянең һәм халыкның дошманнарына каршы большевистик нык торучанлык һәм килешмәүчәнлек күрсәтүегез белән Сез коммунизмның бөек байрагын якладыгыз һәм яклыйсыз.

Безнең Совет Социалистик Республикалар Союзының төзелешендә Сезнең хезмәтләрегез гаять зур һәм бәя биреп җиткергесез. Эшчеләрнең һәм крестьяннарның дөньяда беренче социалистик дәүләте хөкүмәтенең башлыгы булган хәлдә, Сез бөтен дөньяда тынычлык эшен нык уткәргән хәлдә, безнең бөек Ватаныбызның куәтен армый-талмый ныгытасыз.

Советлар Союзының Сезнең турыдан-туры җитәкчелегез астында тормышка ашырыла торган акыллы тынычлык политикасы бөек Ватаныбызның куәтен тагын да ныгытты һәм Совет дәүләтенең халыкара авторитетын моңа кадәр булмаган югарылыкка күтәрде.

Сезнең, иптәш **Молотов**, гүзәл тормыш юлыгыз Ленин—Сталин типындагы политик эшлеклеләр кадрларын тәрбияләүнең иң яхшы үрнәге булып хезмәт итте һәм итә.

Реакциянең һәм караңгы подпольенең каты елларында Сез большевистик оешма төзү буенча зур революцион эш алып барган Казан шәһәрендә һәм бөтен Татарстанда һәрбер хезмәт иясе Сезнең исмегезне кайнар мәхәббәт белән әйтә.

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы, Татарстан Республикасының барлык хезмәт ияләре кебек үк, Сезгә, кадерле Вячеслав Михайлович, безнең куәтле державабызның—Советлар иленең—бәхте өчен күп еллар яшәвегезне һәм нәтиҗәле рәвештә эшләвегезне, коммунизмның бөек эшенә хезмәт итү өчен сәламәтлегегезне һәм көчегезне саклауны тели.

Яшәсен Бөтенсоюз Коммунистлар (большевиклар) Партиясе!

Яшәсен большевистик партиянең турылыклы улы, бөек Сталинның иң яхшы көрәштәше—Вячеслав Михайлович Молотов!

Яшәсен социалистик дәүләтнең юлбашчысы Бөек Сталин!

ТАТАРСТАН АССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ.

ИПТӘШ МОЛОТОВКА

Кадерле Вячеслав Михайлович!

Татарстан АССР Совнаркомы Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасының барлык эшчеләре, колхозчылары һәм интеллигенциясе белән берлектә, Сезнең илле еллыгыгыз көнендә Сезгә, данлыклы большевистик партиянең күренекле оештыручыларыннан һәм җитәкчеләреннән берсенә, пролетар революциянең даһи стратеглары Лениннең һәм Сталинның турылыклы һәм тайпылышсыз шәкертенә һәм көрәштәшенә, куәтле социалистик дәүләтнең Совет Хөкүмәте башлыгына большевистик кайнар сәлам җибәрә.

Социалистик Ватаныбызда иптәш Сталинның даһи җитәкчелегендә ирешелгән бөтен дөнья күләмендәге тарихи җиңүләр, Вячеслав Михайлович, Сезнең исмегез белән нык бәйләнгән.

Ленин—Сталин партиясе эшенә чын күңелдән бирелгәнлегегез белән, партия һәм совет халкы дошманнарына каршы килешмәүчән көрәшүегез белән, социалистик дәүләтне төзү буенча армыйталмый эшләвегез белән, Ленин—Сталин милли политикасын эзлекле рәвештә тормышка ашыруыгыз белән Сез, күп милләтле Советлар Союзы хезмәт ияләренең кайнар мәхәббәтен һәм хөрмәтен казандыгыз.

Партиябезнең даһи Сталинчыл политикасын эзлекле рәвештә тормышка ашырып, Сезнең җитәкчелегегездә илебез ныклы крепость булып үсте, социалистик Ватанның барлык дошманнары бу крепостька бәрелеп үзләренең башларын ватарлар. Татарстан АССР Совнаркомы һәм хезмәт ияләре данлыклы илле еллыгыгыз көнендә, кадерле Вячеслав Михайлович, хезмәт ияләре файдасына Сезнең тагын озак еллар яшәвегезне һәм эшләвегезне телиләр.

Татарстан АССР Совнаркомы.

ТАТАРСТАН АССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ УКАЗЫ

Иптәш Сөләйман Хәлил улы Гафиятуллинны Татарстан АССР Совнаркомы Председателе итеп билгеләү турында

Иптәш Сөләйман Хәлил улы Гафиятуллинны Татарстан Автономияле Совет Социалистик республикасы Халык Комиссарлары Советы председателе итеп билгеләргә.

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы председателе
Г. ДИНМӨХӘМЕТОВ.

Президиум секретаре өчен
Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы члены
Г. ИШМУРАТОВА.

Казан, Кремль.
10 март, 1940 ел.

СӨЛӘЙМАН ХӘЛИЛ УЛЫ ГАФИЯТУЛЛИН

(Кыскача биографиясе)

Сөләйман Хәлил улы Гафиятуллин 1905 нче елны Чистай шәһәрендә эшче - плотник семьясендә туган. 1922 нче елга кадәр ата-аналары тәрбиясендә тора. 1913—1919 нчы елларда укып

6 классны тәмам итә. 1919 нчы елдан алып 1922 нче елга кадәр Чистай шәһәрендәге педагогия техникумында укый. 1922 нче ел Гафиятуллиннар семьясенә бәхетсезлек алып килә—бу елны семья башлыгы Хәлил үлә һәм 5 кешедән гыйбарәт булган семья Сөләйман тәрбиясендә кала.

1922—1927 нче елларда Сөләйман иптәш Гафиятуллин Чистай шәһәрендә пожар охранасында рядовой булып эшли. 1927—28 нче елларда ул пожар-техник курсларында укып, аларны тәмам итә һәм шуннан соң ТАССР ның пожар охранасы управлениесендә башта инспектор, аннары өлкән инспектор булып эшли. Бу, инспекторлык эше, 1932 нче елга кадәр дәвам итә. 1932 — 1938 нче елларда иптәш Гафиятуллин Серго Орджоникидзе исмендәге заводның пожарный охранасы начальнигы булып эшли, шул ук вакытта завод коллективында пропагандистлык эше алып бара. 1937 нче елны иптәш Гафиятуллин ВКП(б) ның Ленин райкомының пленум члены итеп, 1938 нче елның маенда шул ук райкомның икенче секретаре итеп, июль аенда беренче секретаре итеп сайлана һәм шунда 1939 нчы елның апрель аена кадәр эшли. 1939 нчы елның апреленнән алып хәзергә кадәр ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитетының кадрлар буенча секретаре булып эшли. ВКП(б) ның Татарстан оешмасының XX нче өлкә конференциясендә иптәш Гафиятуллин ВКП(б) ның XVIII нче съездына делегат итеп сайланган иде һәм съездның эшләрендә катнашты. Җирле Советларга сайлаулар вактында иптәш Гафиятуллин хезмәт ияләре депутатларының Казан Шәһәр Советы депутаты итеп сайланды. 1930 нчы елдан ВКП(б) члены.

ЯРЫШ БАЙРАГЫН ЮГАРЫ ТОТАБЫЗ

Буа районының барлык мәктәпләрендә Татарстанның XX еллыгына багышланган социалистик ярыш киң җәелә. 11 тулы булмаган урта мәктәп, 4 урта мәктәп үзара ярыш договорлары төзеп, эшкә башладылар. Буа шәһәренең урта мәктәбе укучылары һәм укытучылары укуның сыйфатын күтәрүгә зур игтибар бирәләр. Бирелә массовый оборона эше дә шактый көчәйде. 230 укучы Осоавиахим оешмасында член булып тора, 110 укучы ПВХО га норма тапшырды, 14 укучы Ворошиловча атучы. IX—X нчы классларда йомшак укучы берничә бала бар иде, хәзер инде алар да уку елын отличного тәмамларга йөкләмә алдылар. Рунга урта мәктәбе укучылары, укытучылары үз араларында ярышны киң җәелдереп, Сук-Су тулы булмаган урта мәктәбенең эшен тикшерделәр. Шулай ук Килдураз урта мәктәбендә дә социалистик ярышның нәтиҗәләре тикшерелде. Бу мәктәптә дә 27 укучы ПВХО га, 27 укучы ГСО га норма тапшырдылар. Хәзерге көндә мәктәпләрнең тарихын төзү өчен материал җыйнау бара. Шулай ук мәктәпләр район күләмендә үткәрелә торган олимпиадага катнашу өчен дә хәзерләнәләр. Пионерларның һәм мәктәп балаларының оборонага хәзерлекләрен тикшерү буенча 10 нчы марттан башлап 25 нче мартка чаклы ярышлар үткәрелә.

Хөсәенев.

МАТБУГАТКА ПАРТИЯ ҖИТӘКЧЕЛЕГЕ

Авыл район матбугаты һәм түбәнге матбугат киң массаны тәрбияләүдә, хезмәт ияләрен ВКП(б) ның XVIII нче съезды карарларын үтәүгә, Сталинчыл өченче бишьеллыкның политик һәм хуҗалык бурычларын уңышлы үтәүгә туплауда партия райкомнары кулында көчле корал.

Райкомнар газеталарга идея һәм оештыру ягыннан җитәкчелекне яхшырту эше белән көн саен шөгыльләнә торган урыннарда хуҗалыкның уңышлары зур, партияполитик эш яхшы һәм партоешмаларның масса белән элемтәсе көчле.

Бер характерлы мисаль китерик. Минзәлә районында чыга торган „Знамя Ленина" һәм „Ленин Байрагы" газеталары узган елга кадәр артта калган газеталар булып саналалар иде. Алар районның тормышын тиешенчә яктырта алмадылар һәм хезмәт ияләреннән килгән хатларга саксыз карадылар. Бу газеталарның редакцияләре партоешмалар белән һәм хезмәт ияләре массасы белән ныклы элемтә тотмыйлар иде. Районның хуҗалык һәм политик тормышына газеталарның йогынтысы җитәрлек түгел иде.

ВКП(б) Өлкә Комитеты бу газеталар эше турындагы мәсьәләне тикшергәндә, аларның сыйфат һәм идея ягыннан түбән булуларының төп сәбәбе итеп, большевистик матбугатның көченә һәм аның оештыручанлык роленә райкомның бәя биреп җиткермәвен күрсәтте.

Иптәш Хәкимҗанов райком секретаре булып эшли башлагач газеталарның хәле бөтенләй үзгәрде. Ул газеталар эше белән системалы рәвештә шөгыльләнә, эчтәлекләрен әледән-әле тикшереп тора һәм аларның авторитетларын күтәрүгә ярдәм итә. Райком секретаре редакторларны партоешмаларның эше белән системалы рәвештә таныштырып тора, аларга юнәлеш бирә, дөрес язу юлларын өйрәтә. Райком ярдәме белән газеталар күп кенә яңа мәсьәләләрне, мәсәлән, колхозларда звенолар оештыру һәм авыл советларының эше турындагы мәсьәләләрне күтәрделәр. Райком работниклары газеталарда актив катнашалар.

Райком редакцияләрнең эш планнарын системалы рәвештә тикшерә. Газеталарның эше турындагы мәсьәлә райком пленумында да тикшерелде.

Партия җитәкчелеге яхшыргач, газеталарның идея эчтәлекләре дә яхшырды һәм аларның масса белән элемтәләре ныгыды. „Знамя Ленина" һәм „Ленин Байрагы" газеталарының хәзер 400 дән артык хәбәрчеләре бар, шулардан 116 кеше актив рәвештә языша. Алар арасында партия работниклары да, совет активы да, авыл хуҗалыгы алдынгылары да, совет интеллигенциясе вәкилләре дә бар. 1939 нчы елны бу ике газета үзләренең хәбәрчеләреннән биш меңнән артык хәбәр алганнар. Шулардан 70 проценты файдаланылган. „Знамя Ленина" (редакторы иптәш Растатурин) һәм „Ленин Байрагы" (редакторы иптәш Вахитов) газеталары үзләренең барлык эшләрендә хәбәрчеләр активына таянып, үз битләрендә күп кенә яңа темалар һәм кызыклы мәсьәләләр күтәрәләр.

Хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына сайлауларның уңышларын тәэмин итү буенча һәм „Колхозларда җәмагат терлекчелеген үстерү чаралары турында" ВКП(б) Үзәк Комитеты һәм СССР Совнаркомы карарын тормышка ашыру буенча газеталар зур эш үткәрделәр. Алар Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсендә катнашу хокукы өчен көрәшне киң җәелдерделәр, һәрбер гектардан йөз пот уныш алу ярышын җәелдерүгә булыштылар. Бу соңгы мәсьәлә буенча булган материалларны колхоз җитәкчеләре, бригадирлар, агрономнар һәм рядовой колхозчылар язалар. Мәсәлән, „Знамя Ленина" газетасының 8 нче январь номерында „Бригадир—производствоны оештыручы" дигән бит бирелгән. 29 нчы январь номерында „Йөз пот уныш алу өчен ярыш" дигән бүлектә „Красный курган" колхозы председателе, агротехникы, стахановчылары һәм ат караучысы колхозның язгы чәчүгә хәзерлеге турында сөйлиләр. Бу материаллар барсы да массаны туплыйлар, өйрәтәләр һәм тәрбиялиләр.

Газеталар, аеруча характерлы мәсьәләләрне гомумиләштереп, урыннардагы фактларга нигезләп язылган баш мәкаләләрне еш кына урнаштыра башладылар. Партия тормышы һәм колхоз авылы тормышы тулы итеп яктыртыла. „Знамя Ленина" һәм „Ленин Байрагы" газеталары торган саен сугышчан һәм оператив орган булып, хуҗалыкның конкрет бурычларын һәм политик бурычларны хәл итүгә хезмәт ияләре массасын туплаучы орган булып әвереләләр.

Кызганычка каршы, үз газеталарының кадерен белмәүче, гаять зур оештыручы көч сыйфатында алардан файдаланмаучы райкомнар да бар әле. ВКП(б) ның Ютазы һәм Биләр райкомнарын шулар исәбенә кертергә мөмкин. Бу районнарда чыга торган „Голос Стахановца" (редакторы иптәш Пивоваров) һәм „Коммунизмга" (редакторы иптәш Зиннәтуллин) газеталарының битләре тонык һәм күңелсез булалар. Бу газеталар авторлар белән, хәбәрчеләр белән эшләүгә җитәрлек игтибар бирмиләр.

Хезмәт ияләренең хатлары мондa айлар буена хәрәкәтсез яталар, ә аннары архивка ташланалар. Мәсәлән, Ютазы район газетасында, узган елның 10 ае эчендә, авыл хуҗалыгы артеле уставын бозу фактлары турында язылган 14 хәбәр, уку өйләренең эше турында 42 хәбәр, мәктәпләр турында 30 хәбәр, терлекчелек турында 21 хәбәр, ярыш турында 50 хәбәр, хезмәт дисциплинасы турында 60 хәбәр хәрәкәтсез ятканнар, соңыннан архивка ташланганнар.

„Голос Стахановца" редакциясенә колхоз тегермәннәренең эше турында бер хәбәр алынган. Редакция работниклары бу хәбәргә җидди әһәмият бирергә тиешләр иде. Ләкин ул хәбәр ике айдан артык редактор өстәлендә яткан, аннары аны архивка чыгарганнар. Хәбәрчегә: „Материалыгыз искерде, керми" дип җавап биргәннәр. Фактта исә, тегермәннәр турындагы мәсьәлә ул вакытта да кискен мәсьәләләрнең, тар урыннарның берсе булып торган. Шулай итеп, авыл хәбәрчеләренең инициативасын кысалар, аларның газетага язу теләкләрен сүндерәләр.

Биләр райкомының элекке состав работниклары үз газеталарына: „Начар газета, анарда укырлык бер нәрсә дә юк" дип бәя биргәннәр. Ләкин алар, газетаның сыйфаты түбән булуның төп сәбәбе райком тарафыннан җитәкчелекнең түбән булуында икәнен аңларга теләмәгәннәр. Райком секретарьлары газетаның эше белән тирәнтен танышмаганнар, редакторга күрсәтмәләр бирмәгәннәр. Райком редакция аппаратын Ленин—Сталин партиясе эшенә чын күңелдән бирелгән сәләтле работниклар белән ныгыту мәсьәләсенә җавапсыз карап килде.

Партиянең Бондюг һәм Заинский райкомнары да газета кадрларына һәм аларны политик тәрбияләүгә игтибар бирмиләр. Бу район газеталарында зур гына кимчелекләр бар. Шуңа да карамастан, ВКП(б) райкомнары, газетаның сыйфатына зарар китереп, редакция сотрудникларын төрле кампанияләргә файдаланалар.

Күп кенә райкомнар стена газеталарына игтибар бирмиләр. Шул ук Биләр һәм Ютазы районнарында күп кенә редколлегияләр колхозчыларның һәм хезмәткәрләрнең гомуми җыелышларында сайланмаганнар. Кайбер урыннарда газеталарны аерым кешеләрнең үз инициативалары белән чыгару фактлары да бар. Кайбер колхозларда редколлегия составында колхозчылардан бер кеше дә юк.

Түбәнге матбугат эшендәге җитешсезлекләрне бетерү һәм газетаның сыйфатын яхшырту урына, ВКП(б) ның Биләр райкомы стена газеталарына кем җитәкчелек итәргә тиешлеге турында редакцияләр белән бәхәс алып барган. Партиянең Үзәк Комитеты карарларыннан берсендә: „Партячейкаларны һәм район газеталары редакцияләрен актив катнашуга тартып, районның түбәнге матбугатына һәм рабселькорлар арасындагы эшкә райпарткомнар җитәкчелек итәргә тиешләр" диелгән иде. Партия райкомнары һәм газеталар моны истән чыгармаска тиешләр.

Авыл район матбугатына һәм түбәнге матбугатка, аның идея эчтәлегенә партия җитәкчелеген тәэмин итәргә һәм матбугатны тиңдәшсез югарылыкка күтәрергә кирәк. ВКП(б) ның XVIII нче съезды тарафыннан куелган бурычларны уңышлы хәл итү өчен көрәштә газета партия оешмалары кулында тагын да көчлерәк, тагын да үткенрәк корал булып әверелергә тиеш.

П. Леонидов.

ЗУРЛАРНЫ УКЫТУ ЭШЕ ЯХШЫ ОЕШТЫРЫЛГАН

Транспортсоюзның „Октябрьнең XX еллыгы" артелендә зурларны укыту эше яхшы оештырылган. Грамоталылык өчен укучылар, укытучылар арасында социалистик ярыш киң җәелдерелде. 1940 нчы елның беренче январена артельдә аз белемлеләр 75 кеше иде, хәзер шулардан 20 кеше зурлар мәктәбен тәмамлап чыкты.

Аз белемлеләрне укыту белән бер рәттән, рус графикасы нигезендәге яңа алфавитны өйрәнү эше дә алып барыла. Артельдә 83 кеше яңа алфавитны өйрәнергә тиеш иде. Хәзерге көндә 30 кеше яңа алфавитны өйрәнү эшен тәмамлады. Калган 53 кеше якын көннәрдә тәмамлап чыгачак.

Транспортсоюз системасындагы башка артельләр дә „Октябрьнең XX еллыгы" исемендәге артельдән үрнәк алырга тиешләр.

Камалов.

РАСПИСАНИЕ КӨТЕП...

(Махсус хәбәрчебездән)

Сүз район җир бүлеген ничек итеп үзгәртеп кору турында барды. Шушы уңай белән бирелгән сорау район җир бүлеге мөдире иптәш Халитов өчен көтелмәгән нәрсә булып чыкты.

— Ничек?—диде ул бераз гаҗәпләнү белән.

— Җир органнарын үзгәртеп кору турында СССР Совнаркомы һәм ВКП (б) Үзәк Комитеты карарын үтәү буенча сездә нәрсә эшләнә?

— Ә-ә-ә... Безгә Татнаркомзем штатное расписание җибәрмәде әле. Хәзергә точно бер нәрсә дә әйтеп булмый.

Җир органнарын үзгәртеп кору турындагы карарның үтәлеше буенча сүз чыкканда, биредә, ни өчендер, бөтен эшне әнә шулай „штатное расписание" гә кайтарып калдыралар. Бу мәсьәлә турында өлкән агроном Хәбибуллин, терлекчелек секторы мөдире Нигмәтев иптәшләр белән булган беседа вактында да безгә „штатное расписание" дигән сүзне еш ишетергә туры килде.

Без иптәш Халитовны ямannарга җыенмыйбыз. Ул әле райзо аппаратында күптән түгел эшли. (Ләкин яңа работник булу теге яки бу эштә җаваплылыкны һич тә киметми). Без тик ул җитәкчелек итә торган Әгерҗе район җир бүлегендә эшнең әле һаман искечә баруын күрсәтергә телибез.

Җир органнарын үзгәртеп кору турындагы карар, барыннан да элек, аларны производствога якынайтуга, аларның колхозларга җитәкчелеген яхшыртуга, аппаратның оперативлылыгын көчәйтүгә юнәлдерелгән. Әгерҗе район җир бүлегендә утыручы иптәшләр нак менә шуңа төшенеп җитмәгәннәр.

ВКП(б) Үзәк Комитеты һәм СССР Совнаркомының әлеге карарыннан соң биредә аеруча бер үзгәреш тә булмаган диярлек. Район җир бүлеге аппаратын белгечләр белән ныгыту буенча шушы көнгә кадәр җитәрлек чаралар күрелмәгән. Штат буенча булырга тиешле бер агроном җәй аеннан бирле юк. Зоотехникларның урны шулай ук буш тора: участкы зоотехниклары һәм ат асраучылык буенча бер зоотехник җитешми. Бу кадрларны еракtan эзлисе юк. Алар шушы районда, район җир бүлеге җитәкчеләренең күз алдында. Зоотехник иптәш Ишманова райкомолда эш башкаручы булып эшли; зоотехник иптәш Камалеева район газетасы типографиясендә корректорша; зоотехник иптәш Сайманова—Тирсә авылында укытучы. Алар (Саймановадан башкалары) әле күптән түгел шушы районда, шушы район җир бүлегендә эшләгәннәр, шушы районның колхозларына хезмәт күрсәткәннәр. Соңгы вакытта бу иптәшләрне үз эшләренә кайтару турында мәсьәләне „куеп караганнар да" эш чыкмаган. Сүз—сүз булып калган. Теге иптәшләр дә үз урыннарында калганнар. Районның җитәкче оешмалары да сөйләшүдән уза алмаганнар. Шулай итеп, район җир бүлеге дә белгечләр кадры белән ныгытылмый калган.

Районда колхозларга агрономия һәм зоотехника хезмәте күрсәтү һич тә канәгатьләнерлек түгел. Язгы чәчүгә хәзерлек эше акырын бара. Атларны язгы чәчүгә хәзерләү бигрәк тә начар хәлдә. 34 колхоздан алынган мәглүматлар 654 атның уртадан түбән көрлектә һәм 80 атның ябык булуын күрсәтәләр. Түбән көрлектәге атларның саны „Беренче Май" колхозында 45 кә, „Кр. Бодья" колхозында 52 гә җитә. Район җир бүлегенең терлекчелек секторы мөдире иптәш Нигмәтевчә бу хәл, беренче чиратта быел азыкның кысынкы булуыннан килә. Фактлар исә Нигмәтевнең бу сылтавын кире кагалар. Сталин исемендәге колхозда тупас азыклар да һәм көчле азыклар да җитәрлек. Шуңа карамастан 83 атның 68 е уртадан түбән көрлектә һәм 5 се ябык. Бу факт үзе генә дә эшнең „азыкта" гына булмавын, бәлки атларга тәрбия һәм алардан дөрес файдалануның тиешенчә оештырылмавын күрсәтмимени! Әлбәттә, кайбер колхозларда терлек азыгы мәсьәләсе бер кадәр киеренке хәлдә. Аның каравы азыклары үзләреннән арткан колхозлар да шушы районда бит! Ә менә мондый колхозлардагы артык азыкларны азыгы җитмәгән колхозларга көтәргә бирү яки сату тәртибендә үзара ярдәм оештыру эше белән райзо работниклары бик аз шөгыльләнәләр.

Агротехника чараларын үткәрү, җирле ашламалар җыю эшләренең барышы да мактарлык түгел. Басуга тирес чыгару планы 49 процентка, кар тоту—73, көл җыю —35 процентка гына үтәлгән. Колхозларда хезмәтне оештыру бик йомшак тора. Район җир бүлегенең колхозлар белән җанлы элемтәсе начар. Өлкән агроном иптәш Хәбибуллин райзоның „өлкән статистигына" әйләндерелгән.

Соңгы көннәргә чаклы райзо работниклары чәчү орлыгы җитешми дип зарланып йөрделәр. Аларның, хәтта дәүләттән ссуда алырга да исәпләре юк түгел иде. Ләкин соңгы вакытта үткәрелгән тикшерү орлык җитешмәү турында сөйләнүләрнең бер нәрсәгә дә нигезләнмәгән булуын һәм районда орлыкның җитәрлек икәнлеген күрсәтте.

Китерелгән фактлар барсы да Әгерҗе район җир бүлегендә эшнең һаман да үзгәрешсез булуын, работникларның һаман да искечә эшләүләрен, җир органнарын үзгәртеп кору турында ВКП(б) Үзәк Комитеты һәм СССР Совнаркомы карарыннан соң үзләре өчен тиешле нәтиҗәләрне ясамауларын күрсәтәләр. ВКП(б) ның район комитеты һәм район советы башкарма комитеты район җир бүлеге работникларына эшне яңача оештырырга булышырлар дип ышанабыз.

М. Хәмидуллин.

Казан Мехкомбинатының үзәк лабораториясе лаборанткасы, хезмәт ияләре депутатларының Казан Шәһәр Советы депутаты иптәш Камалеттинова үзенең сайлаучылары белән даими элемтә тота. РӘСЕМДӘ: Иптәш Камалеттинова (сулда) йорт хозяйкалары белән беседа ясый.

А. Усольцев фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

ЯЗНЫ КАРШЫЛАГАНДА

(Махсус хәбәрчебездән, телефон буенча)

Һәр кайда яз турында сүз бара. Күп нәрсә язга багышланып эшләнә. Ленин орденлы Актаныш МТС ы усадьбасында иртән дә, кичен дә кызу эш кайный. Мастерскойларда да, конторада да, клубта да, трактор бригадаларында да шулай.

Язгы эш өчен дип барлык тракторларга, тагылма инвентарьга яхшы итеп ремонт ясалган, 130 тонна ягулык һәм майлау материаллары ташып куелган. Качек, насос, бетон, мичкә, литровка, чиләк һәм башка шундый кирәкле әйберләрнең һәрберсе барлык бригадаларда җитәрлек хәзерләнгәннәр.

Өлкән механик Музеевнең ике кучмә мастерскойны тизрәк җиһазландырып бетерәсе, резерв өчен запас частьләрне, инвентарьны тагын да күбрәк хәзерлисе килә. Ул, Минзәләдән алынган 400 сумлык запас частьләрне, Дербешки затонында реставрацияләнгән күп кенә детальләрне ашыгычлык белән кайтару турында кайгырта. Учреждениеләрнең һәм колхозларның 5 автомашинасы ремонттан чыккан. Тагын 12 автомашинаны капиталь һәм агымдагы ремонттан чыгарырга кирәк. Иптәш Музеев шушы эшләрнең барсын да язга кадәр башкару эшен планлаштырган. Ул шуны үтәү өчен тырыша.

Язның якынаю берәүне дә өлешсез калдырмый. Курслар мөдире иптәш Баһаветтинова тәгән өлеш тә зур. Трактор отрядларының бригадирлары өчен оештырылган 10 көнлек курс тәмамланганнан соң, барлык өлкән тракторчылар да шушындый ук курс үтәргә тиешләр.

Тракторчыларга хәзерләү курсында да укучы 30 кешене һәм производстводан аерылмыйча укучы 20 хатын-кызны тиздән тракторчы итеп чыгарырга кирәк. Курста отлично билгесенә укучы Хафәзә, Кафия һәм Рәшидәләр тракторга утырып китү көннәрен ашкынып көтәләр, ә тракторлар аларны көтә. Иптәш Баһаветтинов та ашыга. Трактор отрядларындагы вагоннарны газета - журналлар, музыка кораллары, шашка, шахмат һәм башкалар белән тәэмин итү эше аңар тапшырылган. Боларның барсы да шушы көннәрдә эшләнергә тиеш һәм алар эшләнә.

Өлкән агроном иптәш Дунаев быел Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенә катнашуны сорап гариза биргән. МТС алдынгыларыннан 5 нче мартта 80 нче гариза рәсмиләштерелеп җибәрелгән.

Язны каршылауга багышлап биредә һәр тармакта күп нәрсәләр эшләнгән. Башкарасы эшләр дә бар әле. Колхозлар белән МТС арасында договорларны төзеп бетерү 15 нче мартка билгеләнгән. Монда шулай һәр эшкә конкрет срок куелган, кешеләр беркетелгән. Директор иптәш Садриев бу эшләрне билгеләнгән срогында үтәүгә җитәкчелек итә. Һәр кемгә билгеле бер эш бар, һәр эшнең бер иясе бар.

МТС коллективының производство киңәшмәсендә Калинин МТС ын социалистик ярышка чакыру проекты тикшерелде. Машиналардан файдалану һәм МТС хезмәт күрсәтә торган колхозларда югары иген уңышы алуга ирешү чаралары турында бригадирлар, тракторчылар, комбайнчылар эшлекле тәкъдимнәр керттеләр.

Шулай итеп, Ленин орденлы МТС язгы чәчүгә уңышлы рәвештә хәзерләнгән. Механиклар, бригадирлар, тракторчылар һәм комбайнчылар зур йөкләмәләр алып, бер-берсен социалистик ярышка чакырып, договорлар төзиләр. Бу йөкләмәләрне тулысынча һәм арттырып үтәүгә аларның ышанычлары зур.

Биредә язны әнә шундый кызу эш, матур теләкләр астында каршылыйлар. Югары уңыш өчен көрәш көчәйгәннән-көчәя.

А. Вәлиев.

ТАТАРСТАННЫҢ XX ЕЛЛЫГЫ АЛДЫННАН

КЫЗЫЛ БАЙРАКЛЫ РАЙОН

Тымытык районы укый-яза белмәүчелекне бетерү һәм аз укый-яза белүчеләрне укыту буенча зур уңышларга иреште. Партия, совет оешмаларының турыдан-туры җитәкчелек итүләре аркасында район тоташтан грамоталы район булу алдында тора. Бу эштә ирешкән уңышларын искә алып, Татарстан Совнаркомы Тымытык районын күчмә кызыл байрак белән бүләкләде.

Тымытык районының җирле оешмалары укый-яза белмәүчелекне бетерү һәм аз укый-яза белүчеләрне укыту эшенә зур әһәмият бирделәр. Зурларны укыту эше ВКП(б) ның тарихи XVIII нче съездыннан соң аеруча киң колач алды. ВКП(б) райкомы партия, совет активын авыл советларына беркетте. Райкомның кадрлар буенча секретаре иптәш Вәлиев һәм райсовет башкарма комитеты президиумы председателе иптәш Насибуллин зурлар мәктәпләрендә эшнең торышы белән кызыксынып тордылар һәм авыл советлары, колхозлар арасында төзелгән социалистик ярыш договорларының үтәлешен системалы рәвештә тикшереп бардылар.

РОНО һәм аның мөдире иптәш Хәкимев укый-яза белмәүчелекне тәмам бетерү өчен инспекторларны һәм методистларны аерым авыл советларына беркетте. Бу иптәшләр үзләренә беркетелгән участкыларда укый-яза белмәүчелекне тәмам бетергәнчегә кадәр эшләделәр. Менә методист иптәш Фазлеев. Ул укый-яза белмәүчеләрне укытуны оештыру һәм методик ярдәм күрсәтү өчен 6 колхозга беркетелгән иде. Иптәш Фазлеев үзенә тапшырылган бурычны намус белән үтәде һәм бу колхозларның дәүләт актын алуларына ирешге. Шулай ук, инспекторлардан Сөләйманов, Сагундукова, педкабинет мөдире Сафуанов иптәшләр дә үзләренә беркетелгән участкыларга дәүләт акты тапшырылганга кадәр эшләделәр.

Укый-яза белмәүчелекне бетерү һәм аз укый-яза белүчеләрне укыту эшенә укытучылар да актив катнаштылар. Һәрбер укытучыга кимендә 10 кешене укытып чыгаруны укытучылар үз өсләренә конркет йөкләмә итеп алдылар. Районда бу эшкә 144 укытучы һәм 46 культармеец катнашты.

Райсовет башкарма комитетының президиумы укый-яза белмәүчелекне бетерү эшенә авыл активын киң күләмдә тартып бик яхшы эшләде дип әйтергә кирәк. Чөнки, бу чара үткәрелгәннән соң, авыл советы һәм колхоз председательләре, клуб, уку өе мөдирләре үзләрендә тулы җаваплылык сизеп эшли башладылар. Мәсәлән, „Кызыл Йолдыз" колхозы председателе Хаҗи иптәш Әхметов укый-яза белмәүчелекне бетерү эшен оештырып җибәрү белән бергә, үзе дә 35 кешене укытып чыгарды. Иптәш Яркәев ике ел эчендә 86 кеше укытты.

Укый-яза белмәүчелекне бетерү буенча конкрет чаралар күрү аркасында, районда 1939 нчы елның беренче маена 1.500 кеше укып чыккан иде. Шушы елның март аена бары тик 74 укый-яза белмәүче калды. Алар да укуга тартылганнар.

Үзләренең укый-яза белмәүчелекләрен бетергән иптәшләр үз белемнәрен тагын да күтәрү өстендә тырышып эшлиләр. Менә Фазлый иптәш Шаһиев. Ул үзенең укый-яза белмәүчелеген 1937 нче елда бетергән иде. Хәзерге вакытта иптәш Шаһиев „Ишкәй" колхозының председателе булып эшли. Ул ТАССР Верховный Советының депутаты. Зурлар мәктәбен 1937 нче елны тәмамлап чыккан иптәш Усманов хәзерге вакытта Учәлле авыл советы башкарма комитетының председателе булып эшли.

Татар язуын рус графикасы нигезендәге яңа алфавитка күчерү турында ТАССР Верховный Советы Президиумы указы чыкканнан соң, яңа алфавитны өйрәнү эше районда киң оештырылды. Тат. Шуган авыл советына караган „Эконом" колхозында яңа алфавитны өйрәнү эше районда беренче булып тәмамланды. Монда авыл советы председателе (Хасан күле вакыйгаларендә катнашучы) иптәш Абдуллин һәм тулы булмаган урта мәктәп мөдире иптәш Кәримев аеруча зур эш үткәрделәр. Алар авылның культура көчен тупладылар, күп балалы аналарны аларның үз йортларында укытуны оештырдылар. Биредә укытучылардан Тимбакова, Гайсина, Фәттахова, Вафина, Сафина иптәшләр авыл советына җидди ярдәм күрсәттеләр.

Районда укый-яза белмәүчелекне бетерү эшендә райондагы вакытлы матбугат зур роль уйнады. Район газетасы һәм колхозлардагы стена газеталары укый-яза белмәүчелекне бетерү эшен системалы рәвештә яктыртып бардылар. Алар алдынгыларның эш тәҗрибәләрен уртаклашуны оештырдылар, артта калучыларны каты тәнкыйть уты астына алдылар.

Укый-яза белмәүчелекне бетерү һәм аз укый-яза белүчеләрне укыту буенча Тымытык районының уңышлары, һич шиксез, зур. Һәм Тымытык районы Сталинчыл өченче бишьеллык планда күрсәтелгән төп политик бурычны хәл итүдә ирешкән бу беренче уңышы белән урынлы рәвештә мактана ала.

Укый-яза белмәүчелекне бетерү буенча алынган йөкләмәләрне республикабызның данлыклы XX еллыгына уңышлы рәвештә үтәп чыгу өчен партия, совет, комсомол оешмалары һәм халык мәгарифе органнары Тымытык районы үрнәкләреннән тулысынча файдаланырга тиешләр. Бу эштә тәҗрибәләрдән тулысынча файдаланганда, инициатива күрсәткәндә һәм тырышып, намус белән эшләгәндә без республикабызны тоташтан грамоталы республика итүгә ирешербез, моңа шик юк.

Колхозларда даими звенолар

Доцент С. А. Ильин.

Колхоз бригадасында хезмәтне дөрес оештырмый торып югары иген уңышы алу өчен уңышлы көрәшнең булуы мөмкин түгел.

Алдынгы колхозларның тәҗрибәләре кырчылык, яшелчәчелек һәм бакчачылык бригадаларында даими звено хезмәтне оештыруның иң дөрес формасы булып торуын күрсәтте.

Даими звено ул, бригада эчендә колхозчыларның билгеле бер группасыннан тора. Звеноның составы даими. Һәрбер звенога даими җир участкылары беркетелә. Бу участкыларда звенолар барлык эшләрне үзләре башкаралар һәм иген уңышы мәсьәләсендә җаваплы булалар.

Даими звенолар оештыру бригадада җиргә карата иясезлекне бөтенләйгә бетерә. Даими звено бригадада эш көчләрен дөрес урнаштыруга ярдәм итә һәм бригадага җитәкчелек итүне җиңләйтә. Даими звено булып эшләгәндә бригадада индивидуаль эш башыннан эшләүне кертү һәм эшне учетка алу, эшнең сыйфатына контроль ясау җиңел була.

Әнә шулар нәтиҗәсендә даими звенолар зур уңышларга ирешеп киләләр. Безнең илебездә иген уңышын күтәрү буенча ирешелгән рекорд саннар звено булып эшләү нәтиҗәсе булып торалар. Менә берничә мисаль. Иптәш Чуманов звеносы (Алтай крае) 1938 нче елны бодайның һәр гектарыннан 512 пот иген уңышы алды. Иптәш Сергеева звеносы (Алтай крае) үткән елны бодайның һәр гектарыннан 605 пот уңыш алды. Иптәш Заглада звеносы (Житомир өлкәсе) үткән елны җитеннең һәр гектарыннан 33 центнер сүс һәм 18 центнер орлык уңышы алуга ирешге. Мондый звенолар бездә бик күп. Аларның исемнәре бөтен дөньяга билгеле.

Татарстан АССР колхозларындагы даими звенолар да, үткән елны һава шартлары берникадәр начар булуга карамастан, шактый зур уңыш алуга ирештеләр. Мәсәлән, Юдино районының „Яңа Тормыш" колхозы хезмәтне звено тәртибендә оештыру нәтиҗәсендә үткән елны 90 гектар мәйданда арышның һәр гектарыннан 22—24 центнер уңыш алды. Иптәш Князева звеносы (Куйбышев районы) бодай уңышын райондагы уртача уңыштан 3 тапкыр артыграк алды. Иптәш Ишмөхәметов звеносы (Кукмара районы) җитен сүсе һәм орлык уңышы буенча ике елдан бирле инде районда беренче урынны алып килә һәм ул дәүләткә җитен продукциясе тапшыру планын арттырып үти. Иптәш Домнина звеносы (Акташ районы) үткән елны среднерусский киндеренең һәр гектарыннан 7 центнер сүс алып, дәүләткә сүс тапшыру планын 12 тапкыр арттырып үтәде.

Мондый мисальләр бик күп һәм алар хезмәтне звено тәртибендә оештыруның иген уңышын күтәрүдә никадәр көчле чара булуын ачык күрсәтеп торалар.

ВКП(б) ның XVIII нче съезды карарларында колхозларда даими звенолар оештырырга тәкъдим ителгән иде. Ләкин Татарстан АССР колхозларында звенолар төзү, алар белән эшләү начар әле. 1939 нчы елның язында оештырылган күп кенә звенолар ел уртасы килеп җиткәч таралдылар. бу кимчелек быел нык лап искә алынырга тиеш. Язны көтмәстән, барлык колхозларда да хәзер үк даими звенолар оештырырга кирәк. Моннан элек оештырылган звеноларны һәр яклап ныгытырга һәм иген уңышын күтәрү буенча аларның эшен тәртипкә салырга кирәк.

Звеноларга җир участкыларын беркетү көздән үткәрелергә тиеш. Звенолар үз участкыларында көзге эшләрне һәм кышкы барлык агрономия чараларын үткәрергә: тирес чыгарырга, кар тотарга һәм язгы кар суларын тотуга хәзерлек чаралары үткәрергә тиешләр.

Бригададагы барлык культура чәчүлекләрен дә звенолар арасында тигезләп бүлү шарт түгел. Әгәр дә культуралар тигезләп бүленсә звенолардагы участкылар саны бик күп булыр иде. Нәтиҗәдә, звенолар үзләрендәге көчне төрле участкыларга сибәргә һәм бер участкыдан икенчесенә күчеп йөрү өчен бик күп вакытларын әрәм итәргә мәҗбүр булачаклар. Чәчүлекләрне звенолар арасында тигезләп бүлү участкыларны бик ваклауга алып бара, ә бу исә һәр бер звеноның иген уңышын төгәл учетка алуны читенләштерәчәк. Шуңа күрә дә, звеноларга беркетелгән участкыларның саны мөмкин кадәр аз булуга игътибар бирергә кирәк. Ләкин, звенодагы барлык эш көчләреннән ел буенча тулысынча һәм тигез файдаланырлык булсын. Бу теләк өчен, кырчылык бригадасында һәрбер звенога уҗым культурасыннан бер культура, башаклы сабан культураларыннан бер, кузаклы бөртеклеләрдән бер культура, үләннәрдән (бер еллык яисә күп еллыклардан) бер культура һәм сызма культуралардан бер культура беркетергә кирәк. Шуннан тыш тагын һәрбер звенога чиста пар басуыннан һәм табигый печәнлекләрдән участкылар беркетелә. Звенолар үзләренең сабан чәчүлекләре участкыларында кышкы агрономия чараларын да, чәчүне дә, урып-җыюны да үткәрәләр. Камыл лущить итү, туңга сөрү яисә кара пар сөрү эшләрен дә звенолар башкара. Пар участкылары ике елга беркетеләләр. Күп еллык үлән чәчү участкылары кышкы агрономия чараларын үткәрүдән һәм чәчүдән башлап, аларны соңгы тапкыр чабып алу һәм шул участкыда көз көне җирне сөреп калдырганга кадәр булган чорга беркетеләләр. Участкыларны беренче тапкыр беркетү сроклары үткәч, ул участкыларны элек эшләгән звеноларга беркетүгә нык игътибар бирергә кирәк.

Звеноларга беркетелгән участкыларны колхозның җир планы копиясенә төшерергә, ә яз көне, кар киткәннән соң аларны күрсәткеч вешкалар куеп яки баганалар утыртып натурада аерып куярга кирәк.

Бригададагы хезмәткә яраклы колхозчыларның (ат караучылардан, трактор бригадасына хезмәт күрсәтүчеләрдән һәм бригадирның үзеннән башкаларны), барсын да звеноларга бүләргә кирәк. Звено үзенә беркетелгән участкыларда барлык төп эшләрне үзендәге көч белән башкарырлык булсын. Звенодагы кешеләр санын билгеләгәндә әнә шуннан чыгып эш итәргә кирәк. Звенода, чама белән әйткәндә, 7—10 кеше була. Эшнең күпчелеге тракторлар белән башкарыла торган колхозларда исә звеноларның күләме кечерәк булуы да мөмкин. Звено өчен кешеләр сайлап алганда кемнең кемнәр белән бергә һәм кайсы звенода эшләргә теләвен, тору урыннарын хисапка алып эш итәргә кирәк. Квалификацияле колхозчылар һәм шулай ук ирләр һәм хатын-кызлар барлык звеноларга да мөмкин кадәр тигезрәк бүленергә тиеш. Бу эшне колхоз правлениесе, бригадир һәм звеновод берлектә эшләргә тиеш.

Звеноводлар итеп ударникларны, стахановчыларны, намус белән эшләүче, дисциплиналы кешеләрне һәм үз эшен яхшы белүчеләрне билгеләргә кирәк. Звено башлыгы барлык эшләргә катнаша, звенога җитәкчелек итә, бригадирга булыша, звено членнарының эш сыйфатына контроль ясый, звенода нык дисциплина булдыру өчен көрәшә, звенода социалистик ярышны оештыра. Звеноводка һәр ай саен 2—3 процент чамасында өстәмә рәвештә хезмәт көне языла.

Авыл хуҗалыгы машиналарын, инвентарьларны, сбруйларны һәм шулай ук тарту көчләрен звенога беркетергә кирәкми. Ә инде үзләренә атлар, машиналар һәм инвентарь беркетелгән колхозчыларны звеноларга тигез бүлүгә нык игътибар итәргә кирәк.

Һәрбер звеноның еллык производство заданиесе булырга һәм анда түбәндәге нәрсәләр күрсәтелергә тиеш: 1) звенога беркетелгән җир участкыларының мәйданы һәм чәчү әйләнеше басулары буенча культуралар, 2) уңыш алу заданиесе, 3) агрономия чараларының төгәл планы.

Звеноның еллык производство заданиесен төзегәндә звеноның барлык членнары катнаша. Еллык производство заданиесе нигезендә һәр участкы һәм культураларның характерын учетка алып, колхоздагы барлык минераль ашламалар, тирес, торф һәм башка ашламалар запасы звенолар арасында планлаштырылырга тиеш. Еллык производство заданиесен үтәү һәм арттырып үтәү өчен һәрбер звено җирле ашламалар (көл, фекаль, кош тизәге, компост ашлама һ. б.) хәзерләүне оештырырга тиеш.

Звено эчендә эш индивидуаль эш башыннан эшләү нигезендә оештырыла. Кыр эшләрендә һәрбер колхозчыга 1—2 көнгә җитәрлек индивидуаль загоннар билгеләнә. Берничә колхозчы тарафыннан бергәләп башкарылырга тиешле эш (мәсәлән, сабан белән бәрәңге утырту, ашлык сугу, орлык тазарту һ. б.) вак группа булып эш башыннан эшләү нигезендә үтәлә. Колхозчылар башкарган эшне звеновод түгел, ә бригадир үзе кабул итәргә тиеш.

Иген уңышы буенча планны арттырып үтәгән звенолар хөкүмәт законнары буенча премия алалар. Бу премия звено эчендә һәрбер колхозчының хезмәт көннәре санынннан чыгып бүленә.

Партиянең район һәм авыл оешмалары, совет органнары, беренче чиратта район җир бүлекләре, МТС һәм колхоз җитәкчеләренең бурычы—хезмәтне звено тәртибендә оештыруга чынчынлап керешүдән һәм язгы чәчүне һәр яктан төгәл һәм дөрес итеп оештырылган даими звенолар белән каршы алудан гыйбарәт. Язгы чәчү якынлашып килә. Даими звенолар оештыруны тизрәк төгәлләргә кирәк.

Чит илләрдә

КӨНБАТЫШ ЕВРОПА СУГЫШЫ

ПАРИЖ, 9 март. Рәсми рәвештә хәбәр итүләренә караганда, кичә Вогезның көнбатыш сыртында француз һәм немец отрядлары арасында бәрелеш булган һәм ул французлар өчен уңышлы тәгәлләнгән. Төнлә фронтта бер нинди яңалык булмаган.

ЛОНДОН, 9 март. Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Англиянең 5.068 тонна авырлыгындагы „Каунселлор" пароходы дошманның һөҗүме нәтиҗәсендә Англиянең төньяк-көнбатыш ярь буенда баткан. Команда коткарылган.

Голландиянең 1.965 тонна авырлыгындагы „Вехт" пароходы Төньяк дингездә батканлыгы дип уйлыйлар. Балык тоту судносы аның коткару көймәсендәге кешеләрне алган. Пароходның командасы 22 кешедән тора иде.

Германиянең 5.846 тонна авырлыгындагы „Уругвай" пароходы Норвегиянең төньяк ярь буенда үз командасы тарафыннан батырылган. Командасының 14 офицеры һәм 40 матросы „Уругвай"ны эзәрлекләп барган Англия сугыш карабы бортына алынган.

НЬЮ-ЙОРК, 9 март. Төньяк дингездә коткару көймәсе табылган. Аңа Голландиянең „Грутто" пароходының исеме язылган. Аның 18 кешедән торган командасы һәлак булганлыгы дип уйланыла.

БЕРЛИН, 9 март. Германия армиясенең верховный командованиесе хәбәр итә: „Көнбатыш фронтта—артиллериядән атышу һәм патрульләрнең хәрәкәтләре. Германия авиациясе Англия өстендә, шулай ук төньяк һәм көнчыгыш Франция өстендә разведка очышлары ясады. Германиянең бер самолеты хәбәрсез югалды.

ЛОНДОН, 8 март. Авиация министрлыгының хәбәр итүенә караганда, сугыш вакты эчендә Англия ярлары якынында Германиянең 45 самолеты бәреп төшерелгән. (ТАСС).

ВӘЗИРСТАНДА ҖӘЗА ЭКСПЕДИЦИЯСЕ

БЕРЛИН, 9 март. (ТАСС). Германия информация бюросының хәбәр итүенә караганда, Италиянең „Аццоне колониале" газетасы Вәзирстанда (Һиндстанның төньяк-көнбатыш чигендәге провинция) кабиләләр восстаниесен Англия гаскәрләре тарафыннан бастыруның барышы турында мәгълүматлар иглан иткән.

Газетаның язуына караганда, гуркларның уңы полкы, 16 нчы Пәнҗаб һәм 18 нче Бәлүҗстан полклары баш күтәрүчеләрнең күп кенә ныгытылган пунктларын алганнар. Беренче Пәнҗаб полкы полиция көчләре ярдәме белән Куррам елгасының көнбатышындагы территориягә (Банну шәһәреннән 12 километр төньяк-көнбатыштарак) кергән.

Баш күтәрүчеләр нык каршылык күрсәтәләр. Бу каршылык күрсәтү җәза экспедициясе командующиенең белдерүеннән дә күренә. Аның сүзенә караганда, „Вәзирстанны тынычландыру өчен бер кадәр вакыт кирәк булачак".

Кытайда сугыш хәрәкәтләре

(ТАСС хәбәрләреннән)

КӨНЬЯК КЫТАЙДА. Гуандун провинциясенең көньягында, Макао атавында японнарның десант частьләре Шици шәһәренә өч яктан һөҗүм алып баралар. Кичә көнбатыштарак японнарның ике колоннасының һөҗүмен туктаттылар.

Кантоннан көнбатыштарак японнар Суйцзян елгасы тамагы районында һөҗүм башладылар.

ТӨНЬЯК КЫТАЙДА. Хэбэй провинциясендә, Бэйпиннән 100 километр көнчыгыштарак зур сугышлар булды. Японнарның 600 ләп кешесе үтерелде һәм яраланды. Бэйпиннән 60 километр көнбатыштарак японнарның һөҗүме кире кагылды.

ҮЗӘК КЫТАЙДА. Хубэй провинциясенең төньяк-көнчыгышында, Суйчжоудан көнбатыштарак кытайлар ике пунктны алдылар. 4 нче мартта бу районда японнарның мең кешелек отряды һөҗүм башлады, ләкин 200 ләп кешесе үтерелгәннән һәм яраланганнан соң, элекке позицияләргә чигенде. Кичә Нинбодан көнчыгыштарак, Люхэн атавында японнар десант гаскәрләре төшерделәр. Кытайлар оборонасы ныклы каршылык күрсәтә.

ВАН ЦЗИН-ВЕЙ ЯПОННАРДАН 40 МИЛЛИОН ДОЛЛАР АКЧА АЛГАН

ЧУНЦИН, 9 март. (ТАСС). Сентрал Ньюс агентлыгының хәбәр итүенә караганда, 24 нче февральдә Ван Цзин-вей Япониянең Иокагама Спеши Бэнк банкыннан яңа „үзәк хөкүмәт" төзү расходларына 40 миллион доллар акча алган.

ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ИПТӘШ МОЛОТОВНЫҢ 50 ЕЛЛЫГЫН ИСТӘ КАЛДЫРАЛАР

КАЗАН ҖИТЕН КОМБИНАТЫНДА

9 нчы мартта, көндезге аш вактында, житен комбинатының цехларында һәм бүлекләрендә Совет хөкүмәте башлыгы иптәш В. М. Молотовның 50 еллыгы турында беседалар үткәрелде. 12 агитатор эшчеләрне иптәш Молотовның тормышы һәм эше белән таныштырдылар. Комбинатның пар-көч хуҗалыгы мастеры иптәш Тимофеев казан цехы эшчеләренең җыелышында, Дубкида булган яшерен җыелышта иптәш Молотов белән очрашуы турындагы истәлекләр белән чыкты.

Иптәш В. М. Молотовның 50 еллыгына багышлап туку фабрикасында стена газетасының махсус номеры чыгарылды.

ТЕЛӘЧЕ РАЙОНЫ

9 нчы мартта, Теләче район клубында, иптәш Молотовның 50 еллыгына багышлап район үзәгендәге хезмәт ияләренең җыелышы булды. Ленинның һәм Сталинның иң якын көрәштәше, большевистик партиянең турылыклы улы, Совет хөкүмәте башлыгы Вячеслав Михайлович Молотовның революцион эше турында урта мәктәп директоры иптәш Миронов доклад ясады. Җыелыш иптәш Молотовны Ленин ордены белән бүләкләү турындагы хәбәрне көчле кул чабулар белән каршы алды.

Агитколлектив җитәкчеләре районның барлык колхозларында һәм мәктәпләрендә иптәш Молотовның 50 еллыгы турында беседалар үткәрделәр.

КЫЗЫЛ АРМИЯ РАЙОНЫ

9 нчы мартта, „Марс", „Восход", „1 нче Май", „Алга №1" колхозларында, Карл Маркс исемендәге колхозда һәм башкаларда В. М. Молотовның 50 еллыгына багышланган җыелышлар булды. Райкомның пропагандистлары һәм агитаторлары колхозчыларны иптәш В. М. Молотовның биографиясе белән, социалистик җәмгыять төзү эшендә аның роле белән таныштырдылар.

Райкомның парткабинеты иптәш Молотовның тормышына һәм революцион эшенә багышлап, күргәзмә оештырды.

(ТатТАСС).

КАЗАН ШӘҺӘРЕНЕҢ ҮЗӘК МУЗЕЕНДӘ КҮРГӘЗМӘ

В. М. Молотовның 50 еллыгына багышлап, Казан Үзәк музеенда күргәзмә ачылды.

Күргәзмәнең экспонатлары (фотографияләр, документларның күчермәләре, портретлар, газета материаллары һәм башкалар) иптәш Молотовның тормышын һәм революцион хезмәтен чагылдыралар.

Фотографияләр арасында: Вячеслав Михайлович Молотов сөргендә вакытта яшәгән йортның рәсме, В. М. Молотовның һәм Н. К. Крупскаяның 1919 нчы елны кызыл армеецлар митингысында алынган фото рәсемнәре, иптәш Молотовның Иркутскида сөргендә вакытта төшерелгән фото рәсме һәм башкалар бар.

Вячеслав Михайловичның Казанда яшәгән чорын чагылдыра торган экспонатлар: иптәш Молотов укыган реальный училище рәсме, Казан жандармерия идарәсе документларының күчермәләре, иптәш Молотовта тентү ясау өчен бирелгән ордер һәм башкалар күргәзмәне караучыларның игтибарын үзләренә тарталар. Бу документларда иптәш В. М. Молотовның Казан шәһәрендәге урта мәктәп укучылары арасында актив революцион эш алып барганлыгы күрсәтелә.

(ТатТАСС).

Бауман районындагы 11 нче номерлы мәктәптә художество үзешчәнлеге смотры. РӘСЕМДӘ: 4 нче класс укучысы Люся Храмышева украин биюен башкара.

А. Попов фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

ТАТАРСТАНДА

— Абортларны тыю турындагы карар чыкканнан соң, Мамадыш районында бала туу саны бик нык үсте. 1939 нчы елның 4 нче кварталында, 1938 нче елның шул ук кварталы белән чагыштырганда, районда бала туу 127 процент арткан. Үткән ел күп балалы аналарга район күләмендә 416 мең сум пособие бирелгән. Бала тудыру йортлары төзелешенә 91 мең сум, сөт кухнялары төзелешенә 8.400 сум, яслеләр ачу өчен 149 мең 700 сум, акушерлык пункты төзелешенә 5.000 сум һәм балалар бакчалары ачуга 138 мең 100 сум акча тотылган.

— Казанның Сталин районында торак төзелеше һәм ремонт планы үткән ел 107 процент итеп үтәлгән иде. Торак төзелеше һәм ремонт эшләре 1940 нчы елда да киң күләмдә үткәрелә. Быел районда 65 урында яңа төзелеш һәм ремонт эшләре алып барылачак. Киров урамындагы 12 нче номерлы йортка өскормә корыла, Сабанчы урамындагы 30 нчы номерлы йорт сүтеп яңадан корыла һ. б. Болар өстенә үткән елдан калган 13 яңа объект эксплоатациягә биреләчәк.

— Үткән ел Казанның Нәриман, Тукай һәм Зур Ямашев урамнарын төзекләндерү эшенә керешелгән иде. Җир кибү белән урамнарны төзекләндерү эшләре быел да дәвам иттереләчәк. Бу урамнарга таш түшәү һәм асфальт җәю эшләренә бер миллион сум акча тотыла. Бер үк вакытта Тукай урамында канализация эшләре дә алып барылачак.

— Казан университеты педагогия, фәнни-тикшеренү һәм оборона-масса эшләрен яхшы оештыру буенча 2 елдан бирле Саратов университеты белән ярыша. Саратов университетының алган йөкләмәләрен үтәвен тикшерү өчен Казан университетының профессор Дюков, химия факультеты деканы Фәйзуллин, студент Московкин иптәшләр составындагы бригадасы Саратовка бара.

— Узган ел Татарстан Кинофекация трестының кино-театрлары аркылы 7 миллион 667 мең тамашачы үткән. Шул исәптән Казан шәһәре кино-театрлары 2 миллион 971 мең кешене үткәргәннәр.

Ш. КАМАЛ ИҖАДЫНА БАГЫШЛАНГАН КИЧӘ

Атаклы татар язучысы иптәш Ш. Камалның 30 еллык юбилеенә хәзерлек уңае белән шушы көннәрдә Бөгелмә шәһәре китапханәсендә кичә үткәрелде. Кичәдә урта мәктәп укытучысы иптәш Әхтәмова Ш. Камалның тормышы һәм иҗады турында доклад ясады. Докладтан соң татар урта мәктәбе укытучыларының үзешчәнлек сәнгате түгәрәге тарафыннан концерт бирелде. Кичәдә 150 дән артык кеше катнашты.

М. Хәйруллин.

21 миллион сумлык аяк киемнәре

Кожвалпромсоюз артельләре Татарстанның промкооперациясе системасында күренекле урынны тоталар. Казандагы һәм районнардагы 14 артель тарафыннан узган ел 18 миллион 515 мең сумлык киез итек һәм күн аяк киемнәре эшләнгән иде. Быел алар 21 миллион 183 мең сумлык продукция бирәчәкләр.

Саба һәм Питрәч районнарында яңа ике артель төзелә. Алар индивидуаль заказ буенча киез итек эшләп чыгарачаклар. 1940 нчы елда артельләрнең мастерскойларын механикалаштыруга һәм яңа төзү эшләренә 620 мең сум акча билгеләнде.

Электромонтерлар хәзерләү курслары

3 нче номерлы мех фабрикасында электромонтерлар хәзерләү өчен 3 айлык курслар оештырылды. Курсларда 18 кеше укый, аларның күпчелеге хатын-кызлар.

Комсомолкалардан Вәлиева, Аширова, Соловцева, Федотова һ. б. иптәшләр электр эшен зур кызыксыну белән өйрәнәләр.

(ТатТАСС).

СУД

АТ БАРЫШНИГЫ

Кукмара районының 1 нче участкы халык суды Гайфеттин Гыймадеттинов дигән спекулянтның эшен карады.

Элекке кулак Гыймадеттинов үзенең иске гадәте буенча атлар белән сәүдә итеп килгән. Ул Удмуртия АССР ның Можга шәһәренә күп тапкырлар барып, атлар алып кайткан, 500 һәм 1.000 сумга алган атларны „Ярыш" колхозына һәм башка учреждениеләргә 1.500 һәм 2.000 сумга саткан.

Халык суды Гыймадеттиновны 6 елга иркеннән мәхрүм итүгә хөкем итте. Татарстан АССР Верховный суды хөкем карарын раслады.

КӨНДӘЛЕК ВАКЫЙГАЛӘР

ХУЛИГАННАР. Бер көнне кичен Казан шәһәренең Бауман урамыннан үтеп баручылар 8 нче номерлы ашханәдә пияла ватылган тавышларны ишеткәннәр. Ашханә залына кергән гражданнар, анда зур тавыш куптарган 3 хулиганны күргәннәр. Хулиганнар ашханә хезмәткәрләренә бәйләнгәннәр, төрле кешеләрне кыйнаганнар һәм савыт-сабаларны ватып 770 сум зарар китергәннәр. Шаһиәхмәт Галиәхметов, Габделхак Динмөхәмәтов һәм Гаян Шәрипов дигән бу хулиганнар тотылып, суд җаваплылыгына тартылганнар.

Вахитов исемендәге Жиркомбинат директоры, ВКП(б) члены, ВКП(б) ның Сталин Райкомы ревизия комиссиясе члены иптәш

Зиннәт Вәли улы
ВӘЛИЕВ

нең шушы ел 9 нчы мартта, озак дәвам итмәгән авырудан, вакытсыз үлүен ВКП(б) ның Казан шәһәре, Сталин Район Комитеты тирән кайгы белән белдерә һәм аның семьясенең кайгысын уртаклаша.

Главражирмасло Казан Сәүдә базасының бөтен коллективы Вахитов исемендәге Жиркомбинат директоры

Зиннәт Вәли улы
ВӘЛИЕВ

нең вакытсыз үлүен тирән кайгы белән белдерә һәм аның семьясенең кайгысын уртаклаша.

461—1

Вахитов исемендәге Жиркомбинат директоры

Зиннәт Вәли улы
Вәлиевне күмү

процессы 11 нче мартта үткәрелә
Тәүдәсе Жиркомбинат клубыннан көндез 2 сәгать 30 минутта алып чыгыла.

ДИРЕКЦИЯ.

468.

Дирекция, завком һәм житештерү бүлеге работникларының коллективы химикатлар группасы начальнигы иптәш

Борис Данилович
ФЕДОРОВ

ның шушы ел 8 нче мартта вакытсыз үлүен тирән кайгы белән белдерәләр һәм аның семьясенең кайгысын уртаклашалар.
Күмү процессы 11 нче мартта көндез 2 сәгатьтә (Ягодный каберлегендә) була.

470—1

Галиәсгар Камал исемендәге
Татар Дәүләт Академия театры
12 нче мартта көндез 12 сәгатьтә һәм кич
БИШБҮЛӘК
талоннар: көндез 132, кич 133.
13 нче мартта
ШӘМСЕКАМӘР
Талон 134.
Спектакль кич 7 сәгать 30 минутта башлана.
Касса һәр көн көндез 11 сәгатьтән 2 гә һәм кич 5 сәгатьтән 9 га кадәр ачык. ТДАТ.

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ
11 нче мартта кич һәм 12 нче мартта көндез
МАСКАРАД
12 нче мартта кич
КУРКЫНЫЧЛЫ БОРЫЛЫШ
Талоннар: бүген 121, иртәгә көндез 24, кич 122.
Коллектив рәвештә килү өчен заявкалар алына.
Спектакльләр кич 7 сәгать 30 минутта башлана.
Билетлар көндез 11 сәгать 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгатьтән 7 сәгать 30 минутка кадәр кассада сатыла.

ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ТЕАТРЫ
Галиәсгар Камал исемендәге Татар Дәүләт Академия театры бинасында
13 нче мартта Зур театр бинасында
ФАУСТ
Талон 87. Кич 7 сәгать 30 минутта башлана.
11 нче мартта ТАССР ның атказанган артисткасы
САРА САДЫЙКОВА КОНЦЕРТЫ
Кич 9 да башлана. Талон 86.
Коллектив рәвештә килү өчен 29—64 телефоны буенча заявкалар алына.

Киров районындагы
КУЛЬТУРА САРАЕНДА
11 һәм 12 нче мартта
Халыкара Хатын-кызлар көненә багышланган
ЗУР КОНЦЕРТ,
КИЧӘ-БАЛ
ДЖАЗ, танцылар.
Кич 7 сәгать 30 минутта башлана.
Талоннар: бүген 66, иртәгә 67. 2—1

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ
Бүген, 11 нче мартта, данлыклы
ЗОЛЛО ТИМЕР ЮЛЫ
300 хайван һәм кошлар катнаша һәм башка күп номерлар.
РСФСР ның атказанган артисты орденлы
М. ЗОЛЛОның
соңгы гастрольләренә билетлар сатыла.
Уен кич 8 дә башлана.
Касса һәр көн көндез 11 сәгатьтән 3 кә һәм кич 5 тән 9 га кадәр ачык.
Иртәгә көндез 12 сәгатьтә зур программа буенча
КӨНДЕЗГЕ ЦИРК УЕНЫ.

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЭЛЕКТРО" 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	Тавышлы, художестволы, чит ил фильмы КАТЕРИНА
„УНИОН" 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	КЕЧКЕНӘ АНА
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ" 6, 8 һәм 10 да	ЯШӘРГӘ
„ЧАТКЫ" 6, 8, 9-30 да.	УТ ТРАНСПОРТЫ
„ПИОНЕР" 11, 1, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	ДҮРТЕНЧЕ ПЕРИСКОП. Көндез 1 сәгатьтә мәктәпкә кадәр яштәге балалар өчен сеанс.
„Колхозник" 6, 8 һәм 10 да.	МИНИН һәм ПОЖАРСКИЙ
„РОТ-ФРОНТ" 6, 8, 10 да.	УКЫТУЧЫ
КУЛЬТУРА САРАЕ 5, 7, 9 да.	ПАТРИОТ

КИРӘК:

Татарстан АССР районнарында мәктәп төзелеше буенча прораб булып эшләү өчен ТӨЗҮЧЕ ТЕХНИКЛАР. Хезмәт хакы килешү буенча. Квартира бирелә. Казан, Кремль, Татнаркомпрос. Телефон № 26—62.
348—2—1

ТАТАРСТАН АССР ЛЕСПРОМХОЗЛАРЫНДА АГАЧ МАТЕРИАЛЛАРЫ ТАШУ БУЕНЧА ДАИМИ РӘВЕШТӘ ЭШЛӘҮ ӨЧЕН ШОФЕРЛАР ҺӘМ ТРАКТОРЧЫЛАР. Эш урыннары: ШӘМӘРДӘН (Казан тимер юлы, Шәмәрдән станциясе), ШИРӘМӘТ һәм ТЕЛЬМАН (Кузнечиха районы, Тумба авылы) леспромхозларында. Казанда Наркомлеска (Толстой урамы, 41), ә урыннарда турыдан-туры леспромхозларга мөрәҗәгать итәргә.
374—2—1

Татнаркомхозның Мелиорация-Гидротехника конторасына ИНЖЕНЕРЛАРДАН: ГИДРОТЕХНИКЛАР, ТӨЗҮЧЕЛӘР, ГИДРОГЕОЛОГЛАР. ТЕХНИКЛАРДАН: ТӨЗҮЧЕЛӘР, ГИДРОТЕХНИК-ИНВЕНТАРИЗАТОРЛАР, САНТЕХНИКЛАР, КОЛЛЕКТОРЛАР, БОРАУЛАУ МАСТЕРЛАРЫ. Шунда ук ЯРДӘМЧЕ ЭШЧЕЛӘР. Казан Кремль, 3 нче подъезд.
330—5—5

„ЛЕНИН"

(А. Каплер һәм Т. Златогорова әсәре, Зур театр, театрның художество җитәкчесе һәм баш режиссеры Я. А. Варшавский постановкасы)

Ленин образын сәнгатьтә чагылдыру—гаять бөек һәм шуның белән бергә катлаулы бурыч. Безнең совет сәнгате хәзер әнә шул катлаулы бурычны уңышлы рәвештә хәл кылу югарылыгына күтәрелеп килә. Соңгы берничә елда кинода һәм театрда Ленин, Сталин образларын чагылдыра башлау, барыннан да элек, совет сәнгатенең күтәрелешен билгели торган матур бер факт булып тора.

Казанның Зур драма театры да, Казанда беренче тапкыр буларак, „Ленин" әсәрен куеп, үзенең үскәнлеген күрсәтте, өлгергәнлеккә имтихан тотты. Спектакльнең аерым җитешсезлекләре булырга мөмкин һәм алар бар да, ләкин, тулаем алганда, һич шиксез, „Ленин" постановкасы театрның быелгы сезондагы иң яхшы постановкасы булып тора.

„Ленин" әсәре „Ленин 1918 нче елда" дигән картинадагы мотивлар буенча язылган. Бу мотивлар совет тамашачысына таныш һәм тамашачы тарафыннан чын йөрәк белән кичерелгән, аны дулкынландырган мотивлар: Советлар властеның беренче еллары. Шәһәрдә һәм авылда эксплоататор сыйныф калдыклары советларга каршы саботаж, спекуляция һәм башка юллар белән көрәш алып баралар. Кулаклар икмәк яшереп һәм икмәк белән спекуляция ясап, илдә, аеруча үзәктә икмәксезлек кыенлыгын көчәйтәләр. Шул ук вакытта яшь Совет иле төрле яктан дошман гаскәре белән чорналып алынган, чит ил капиталистлары Россиядә кабынган революция ялкынын сүндерү, Россияне үзара бүлгәләп алу һәм аның халкын кол итү теләге белән Советларга каршы интервенция алып баралар. Бөтен дөнья контрреволюцион буржуазиясенең төрле төстәге ерелеваклы агентлары—эсерлар, троцкичы-бухаринчы сатлык җаннар чит ил капиталистларына тырышып-тырышып хезмәт күрсәтәләр. Халыкта таянычлары булмаган бу бер төркем пычрак җаннар коточыргыч җинаятькә хәзерләнәләр, кешелек дөньясының якты кояшын сүндерергә, Ленинне юк итәргә уйлыйлар, шул юл белән яшь Совет илен башсыз, кешелек дөньясын кояшсыз калдырып, пролетар революциясне буарга маташалар.

Ләкин алар үзләренең пычрак теләкләренә ирешә алмыйлар. Ленин һәм аның бөек идеясе җиңә; эчке һәм тышкы дошманнарның көчләре сындырыла. Ленин, Сталин җитәкчелеге астында яшь Совет иле ныгый, кыенлыкларны җиңү юлы белән алга таба бара.

Спектакльдә мастерларча эшләнгән аерым урыннар бар. Лениннең крестьяннар һәм чекист Василий белән очрашу картиналары, Дзержинскийның җинаятьче Синцовны фаш итүе, фронттан—Сталиннан шатлыклы хәбәр, җиңү хәбәре килгәннән соң Лениннең аеруча нык күтәрелеп китүе, врачлар белән булган „аңлашылмаулар"—менә болар барсы да бик яхшы эшләнгән һәм тулы бирелә торган күренешләр.

Гомумән, постановщик иптәш Варшавский спектакльне тигез һәм ритмлы спектакль итү өчен зур гына көч куйган, спектакльнең „төшеп кала" торган почмаклары юк, ул башыннан ахрына чаклы җылы һәм тигез сулыш белән ага.

Шулай да аерым рольләрне башкаручылар һәм спектакльнең оформлениесе турында әйтәсе сүзләр бар. Аерым рольләргә килгәндә, иң элек Ленин образына тукталасы килә. Без бу рольдә зур казанышка ирешкән мәрхүм Щукинны һәм башкаларны күргәнбез, шуңа күрә безне хәзер „тулыр-тулмас" тәэсирләр генә канәгатьләндерә алмыйлар, без Ленин образын сәхнәдә бөтен тулылыгы белән күрергә телибез. Периферия театры булу яки булмаса башка кайбер „объектив сәбәпләр" генә биредә театрны коткарып кала алмыйлар.

Кызганычка каршы, Зур драма театрында, артист Борелин башкаруында Ленин образы без күрергә теләгән Ленин образыннан шактый ерак булып чыкты. Артист Борелин Лениннең кайбер тышкы үзенчәлекләрен, сүз сөйләүдә, хәрәкәтләрендә, жестларында булган характерлы якларын бик нык үзләштергән дә, шулар белән артык мавыгып китеп, образның эчке җылылыгын, эмоциональ байлыгын, омтылышчанлыгын тиешенчә ачып җиткерми. Бер сүз белән әйткәндә, артист Борелин тудырган Ленин образында эчке ялкынлылык җитешеп бетми. Ленин образының башкарылуында булган икенче бер кимчелек итеп, иптәш Борелинның тавышы йомшак булу, тавышта ышанычлылык, кискенлек җитмәүне әйтергә кирәк. Шул ук вакытта Борелин тарафыннан уңышлы алып барылган, шактый тулы һәм җанлы бирелгән аерым күренешләрне дә әйтмичә калып булмый (крестьяннәр белән сөйләшү, Лениннең авыру чагы һ. б.).

Сталин образы ТАССР ның халык артисты Ф. В. Григорьев тарафыннан ышандырырлык рәвештә тигез, тулы итеп башкарылды. Григорьев образны тирән аңлап, аның омтылышлы характерын тулы ачу юлы белән барды. Тик грим 1918 нче елгы Сталинны түгел, соңгы еллардагы Сталинны күз алдына китерә иде.

Ф. Э. Дзержинский ролен башкаручы атказанган артист А. Д. Гусев күз алдына куркуны һәм аруны белми торган, батыр, сизгер һәм тынычсыз Феликсны җанлы итеп бастыра алды. Бу роль үзенә тирән мәхәббәт уята һәм тулысынча ышандыра.

Кыска гына роль булса да, Я. М. Свердлов (артист А. И. Дэйчман) образы турында да шуны ук әйтергә туры килә.

А. М. Горький образын ТАССР ның халык артисты Г. Л. Ардаров күп өлеш тулы һәм җанлы итеп үти. Артист Мацкевичның уенында җанлылык җитми. Артист Мацкевич аны авыр сөякле, басынкы, акырын итеп бирергә теләп, аның җылы, тирән тойгылы, бөек кеше булуына азрак әһәмият бирде төсле. Шунлыктан булса кирәк, Максим Горький образы салкын, коры булып чыкты.

Чекист Василий ролендә Загорский, Кремль коменданты Матвеев ролендә ТАССР ның атказанган артисты Ососков образларның чын тирәнлекләренә кереп, бик нык аңлап уйнадылар, табигый һәм тулы характерлар тудырдылар.

Спектакльдә кире типлар да шактый ук оста эшләнгәннәр. Болар арасыннан аеруча нечкә һәм урынына җиткерелеп башкарылган Константинов (артист О. Л. Коховский) һәм мәкерле, астыртын кулак (артист В. А. Гранат) типларын әйтеп үтәргә кирәк. З. Р. Ковалевская башкаруында Каплан җитәрлек ачылмый. Бу роль данга омтылучы сентименталь хатын булып кына сурәтләнә.

Әсәрнең сәхнәгә куелышы турында тулаем алып яхшы дигән фикерне әйткән хәлдә, аерым күренешләрнең кимчелекләренә тукталып, шуны әйтергә була: эсерларның яшерен утырышы күренеше җентекләп эшләнмәгән. Бу күренеш контрреволюцион заговорчыларның социаль йөзләрен, аларның психологик хәлләрен (тынгысызлык, паника, куркаклык һ. б.) тулысы белән ачуга ярдәм итми. Завод алдындагы масса күренеше дә тиешенчә оешып җитмәгән.

Спектакльнең оформлениесендә (художник Н. Бельский) берникадәр ярлылык күзгә бәрелеп тора. Мәсәлән, завод ишек алды, кухня, ложа һәм башкалар әнә шуны күрсәтәләр. Һәр хәлдә, кухня белән Совнарком бүлмәсен чаршау белән генә аермыйча, тулырак, баерак эшләргә булыр иде.

Гомумән алганда, „Ленин" спектакле Зур драма театрының быелгы сезондагы җидди уңышы булып тора.

М. Җәлил, Ф. Хөсни.

Җаваплы редактор
һ. АБДРАХМАНОВ.
Ответ. редактор Х. АБДРАХМАНОВ.

УПОЛН. ГЛАВЛИТА ТАССР. № А — 751 ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА, ДОМ ПЕЧАТИ 1940 ГОД. ЗАКАЗ № 962.